• ВАКЫЙГА •

«ПРИЮТ» ПУНКТЫ ӨЧЕН КАЗАН МӘЧЕТЛӘРЕНДӘ КИЕМ-САЛЫМ, АЗЫК-ТӨЛЕК ҖЫЮ БАРА

*2 бит*

• СОРАУ-ҖАВАП •

НӘФЕЛ НАМАЗЛАР НИНДИ БУЛА ҺӘМ КАЙЧАН УКЫЛА?

*4 бит*

• ЗӘКӘТ •

КӨЗГЕ УҢЫШТАН ГОШЕР СӘДАКАСЫН ТҮЛӘРГӘ ОНЫТМЫЙК!

*7 бит*

• СӘЛАМӘТЛЕК •

ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗНЕҢ ЯРАТКАН ҖИМЕШЛӘРЕНЕҢ ФАЙДАСЫ ТУРЫНДА

*14 бит*

*№ 9 (278)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *зөлхиҗҗә 1439 – мөхәррам 1440*

*Сентябрь, 2018*

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Татарстан Президенты үзенең Юлламасында «Хозур-ТВ»ны югары бәяләде







Татарстан Президенты ТР Дәүләт Советына республиканың эчке һәм тышкы хәле турында еллык юллама белән чыгыш ясады. Чарада Татарстан Республикасы мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты.

Рөстәм Миңнеханов 2018 елның уңышлы, имин һәм вакыйгаларга бай ел булуын әйтеп узды. Аерым алганда, быел Татарстанда Шиһабетдин Мәрҗани елы игълан ителүе турында искә төшерде һәм аның кыса-ларында Мәрҗани мәчете янәшәсендә атаклы татар галиме истәлегенә һәйкәл ачылачагын хәбәр итте.

*Дәвамы 8 биттә*

# Казан мәчетләрендә мохтаҗларга кием җыела

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте чираттагы социаль проектын гамәлгә ашыра башлады. Проект мохтаҗларга бушлай ярдәм күрсәтү буенча «Приют» пункты өчен Казан мәчетләрендә кием-салым, азык-төлек, савыт-саба һәм башка кирәк-яраклар җыюны күз уңында тота. Җомга вәгазьләрендә башкала имамнары мәхәлләләр халкына бу хакта игълан ясады.

Олылар һәм балалар өчен киемсалым, озак бозылмый торган азыктөлек (тоз, шикәр, ярмалар, консервалар һ.б.), савыт-саба, уенчыклар, көнкүреш химиясе товарлары башкаланың түбәндәге мәчетләрендә кабул ителә:

Кабан арты мәчете (Һ. Такташ урамы, 26)

«Гаилә» (Җ. Фәйзи урамы, 2)

«Ярдәм» (Серов урамы, 4а)

«Нур әл-Ислам» (М. Бигиев урамы, 36/56)

«Казан Нуры» (Ф. Әмирхан урамы, 3, корп.2)

«Фатиха» (Кадышево бистәсе, Р. Зорге урамы, 2а)

«Өмет» (Борисоглебский бистәсе, Мәктәп урамы, 4а)

«Салихҗан» (Бестужев урамы, 66а).

Моннан тыш, кирәк-яракларны тәүлек әйләнәсе эшли торган «Приют» ярдәм пунктына да (Б. Шаһиди урамы, 26 нчы йорт) китерергә мөмкин. Белешмә өчен телефон: 8(843) 216-44-01.

«Приют» мохтаҗларга бушлай ярдәм күрсәтү пункты «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация» үзәге тарафыннан оештырылды. Биредә мохтаҗ һәм йортсыз-җирсез калган кешеләр өчен бушлай кайнар аш белән туклану, аларны кием-салым белән тәэмин итү каралган, шулай ук куну һәм юыну өчен шартлар булдырылган. Моннан тыш, мохтаҗларга телефон элемтәсеннән файдалану, эшкә урнашу, югалган документларны торгызуда ярдәм итү, юридик консультацияләр, медицина һ.б. хезмәтләр күрсәтелә. Ярдәм аз керемле гаиләләргә, наркомания һәм алкоголизм чирләреннән интегүчеләргә дә күрсәтелә. Шуны да билгеләп узарга кирәк: ТР мөселманнары Диния нәзарәте мохтаҗларны корбанлыклар белән тәэмин итеп тә әлеге социаль проектны тормышка ашыруга үз өлешен кертә.

■ **dumrt.ru**

# Галиев мәчетендә лекцияләр башлана



1 октябрьдән Галиев мәчетендә ислам диненең актуаль мәсьәләләре буенча ачык лекцияләр циклы үз эшен башлап җибәрә. Ни өчен хәнәфи мәзһәбе буенча гамәл кылу һәм аны саклау мөһим, исламда тарихимәдәни мирасның роле нинди – әлеге һәм башка сорауларга танылган белгечләр: галимнәр, остазлар, имамнар, дин эшлеклеләре җавап бирәчәк.

Шулай итеп, лекцияләр циклын «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең укуукыту эшләре буенча мөдир урынбасары Зөлфәт хәзрәт Габдуллин ачып җибәрәчәк. Остаз һәр дүшәмбе көнне ястү намазыннан соң хәдис дәресләрен бирәчәк. Алга таба һәр сишәмбедә исламның актуаль темалары буенча лекцияләр, вәгазьләр укылачак. Чәршәмбе көнне Татарстан мөфтиенең шәригать мәсьәләләре буенча киңәшчесе Булат хәзрәт Мөбарәков хәнәфи фикһын алып барачак. Пәнҗешәмбе көнне 18.00 сәгатьтә «Мөселман дискуссион клубы» үз эшен башлап җибәрәчәк. Рәхим итегез!

■ **dumrt.ru**

# Казандагы «Сәлах» мәчетен төзеп бетерү өчен матди ярдәм кирәк





Казанның Совет районында «Сәлах» мәчете төзелә. Хәзерге вакытта гыйбадәт йортының эчке ягында төзелеш эшләре дәвам итә. Күптән түгел манара урнаштырылган, мәчет тирәсендәге территорияне тәртипкә китерү эшләре башланган. Әмма төзелешне тулысынча төгәлләү өчен, матди ярдәм кирәк!

Хөрмәтле дин кардәшләребез! Күңелендә изге нияте булган һәркем бу саваплы эшкә кушыла һәм «Сәлах» мәчетен төзүгә үз өлешен кертә ала.

Акчаны 4276 6200 2306 9663 номерлы Сбербанк картасына күчерергә мөмкин (Рифнур Зиннурович Нургалиев картасы).

# Мәчетләрдә татар теле курслары башлана




1 октябрьдән Татарстан мәчетләрендә татар телен өйрәнү курслары башлана. Хәзерге вакытта курсларга язылырга теләүчеләрдән гаризалар кабул ителә.

«Без – татарлар» татар теле курслары Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин башлангычы белән ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан бушлай оештырыла.

Курсларның беренчесе быел февраль – апрель айларында Татарстанның 10 мәчетендә уздырылган булса, бу юлы аларны республиканың барлыгы 20 мәчетендә оештыру күздә тотыла. Аерым алганда, курслар Казанның «Тынычлык», «Ризван», «Гаилә», «Ярдәм», «Әниләр» мәчетләрендә һәм Татарстанның 15 районында – Яр Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Алабуга, Яшел Үзән, Ютазы, Чистай, Спас, Норлат, Менделеевск, Югары Ослан, Алексеевск, Әгерҗе мөхтәсибәтләрендә үткәреләчәк.

Курсларны уздыру вакыты да озайтыла: белем бирү дәвамлылыгы элеккечә 3 айга түгел, ә ярты елга исәпләнгән.

Дәресләр атнасына ике тапкыр оештырыла. Аларны югары белемле филологлар, тәҗрибәле татар теле укытучылары алып барачак. Укыту барышында «Хозур» нәшрияты тарафыннан нәшер ителгән «Татар теле. Башлап өйрәнүчеләр өчен» дәреслеге файдалану күздә тотыла. Дәресләрне уздыру вакыты курсларга йөрүчеләрнең теләген исәпкә алып билгеләнәчәк. Теләүчеләр өчен өстәмә ислам дине мәдәнияте белән танышу мөмкинлеге каралган.

Шунысын билгеләп узарга кирәк: февраль – апрель айларында уздырылган «Без – татарлар» татар теле курсларына язылучыларның саны 500 гә якын булды. Бу юлы, мәчетләр саны артуга бәйле рәвештә, курсларга татар телен өйрәнергә теләүче 1000ләп кеше йөрер, дип фаразлана.

Укыту процессы тәмамлангач, тыңлаучыларга тиешле сертификат тапшыру да каралган.

Курсларга язылу өчен мәчетләргә яки хәзрәтләргә шалтыратырга кирәк. Мәчет телефон номерлары **dumrt.ru** сайтында китерелә.

■ **dumrt.ru**

# «Беренче Мәчкәрә укулары» узды

Кукмара районы Мәчкәрә авылында «Беренче Мәчкәрә укулары» республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе узды. Укуларның темасы – «Мәчкәрә авылының тарихы һәм дини-рухи мирасы». Конференция эшендә күренекле галимнәр, дин белгечләре катнашты. Мәчкәрә укуларына килүчеләрне Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин сәламләде. Шулай ук укуларда Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Кукмара районы имам-мөхтәсибе Рәдиф хәзрәт Тимергалиев, Кукмара мәдрәсәсе мөдире Ришат хәзрәт Курамшин, Мәчкәрә авылы мәчете имам-хатыйбы Мөнир хәзрәт Йосыпов, Апанай мәчете имам-хатыйбы, тарих фәннәре кандидаты Нияз хәзрәт Сабиров, Кукмара музее директоры Ләбүдә Дәүләтшина, тарих фәннәре докторы Наил Таиров чыгышлар ясады.



Конференцияне җыюның сәбәбе булып Мәчкәрәнең бай тарихы тора. Фәнни җыелыш катнашучыларның Мәчкәрә авылы зиратына кереп, галимнәр рухына дога кылуыннан башланып китте. Аннары катнашучылар Мәчкәрә авылының данлыклы Беренче Җәмигъ мәчете белән таныштылар. Мәчеттә бүгенге көндә реставрация эшләре алып барыла. Әлеге мәчетне 1791 елда беренче гильдия сәүдәгәре Габдулла Габдессәлам улы Үтәмешев төзетә. Мәчет манарасының кыйбласын мәгърифәтче, дин белгече Габденнасыйр Курсави күрсәтеп биргән була. 1793 елда ошбу мәчеттә беренче намаз укыла. Габдулла Үтәмешев үзе дә белемле шәхес була, аның дин хакында язылган берничә хезмәте бар. Хәләл җефете Мәрхәбә – Габденнасыйр хәзрәт Курсавиның бертуган сеңлесе.

Туку фабрикалары хуҗасы Габдулла Үтәмешевны Россиядә һәм чит илләрдә юмарт меценат буларак та белгәннәр. Ул Россиядә йөз иллеләп мәчет төзеткән. Башкалабыз Казандагы Иске Таш мәчете дә аның матди ярдәме хисабына торгызылган.

Мәчкәрә авылында дин галимнәре, мәдрәсә остазлары, шәкертләре, милләт һәм дин өчен хезмәт иткән олуг шәхесләр җирләнгән зират бүгенге көнгә кадәр сакланган. Борынгы зират таш койма белән уратып алынган, мәйданы – 3 гектар.

Тирә-юньдәге уку йортлары белән чагыштырганда, мәдрәсәләрнең дәрәҗәсе, абруе ягыннан Сатыш, Иж-Бубый мәдрәсәләре белән тиңләшерлек мәдрәсә Мәчкәрә авылында да була. Аны ислам дөньясында яхшы белгәннәр. Мәчкәрә мәдрәсәсендә Казан, Уфа, Вятка губерналарының руханилары гына түгел, Себердән, башкорт, казах далаларыннан килеп тә белем алганнар. Заманында олуг шәхесләрдән: мәгърифәтче Каюм Насыйриның әтисе; тарихчы, галим Хөсәен Әмирхан, тарикать остазы Мөхәммәдзакир ишан Камалов та башлангыч белемне биредә алганнар. Татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикер тарихында күренекле галим Шиһабетдин Мәрҗанинең бабасы Сөбхан бине Габделкәрим Әл-Мәрҗани (1746-1833) – Мөхәммәдрәхим ахуннан гыйлемлек алган һәм күптөрле фәннәр өйрәнгән. Монда атаклы фикер иясе һәм дин белгече Габденнасыйр Курсави (1771-1812) мәшһүр мелла Мөхәммәдрәхим ахуннан белем алган.

■ **dumrt.ru**

# «Изге Коръәндә һәм Пакъ Сөннәттә мөэмин мөселман образы»

Казанда «Коръәнне борынгы һәм хәзерге чорда тәфсир кылу»: «Изге Коръәндә һәм Пакъ Сөннәттә мөэмин мөселман образы» дип исемләнгән IV Халыкара ислам конференциясе уздырылды. Чараның төп максаты – бүгенге мөэмин мөселман образын Изге Коръәндә һәм Пакъ Сөннәттә күрсәтелгәнчә ачып бирү, шулай ук ММЧда мөселманнарның уңай образын формалыштыру механизмын булдыруга киңәш-тәкъдимнәр эшләү.

Конференция эшендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, шулай ук Россия, Сүрия, Гыйрак, Ливан, Мисыр, Һиндстан, Пакыстан һәм башка илләрдән дин галимнәре, белгечләр катнашты.

«Сөннәт белән Коръәнне аерып карарга ярамый. Сөннәтне кире каккан кеше Изге Коръәнне дә кире кага», – дип билгеләп үтте Камил хәзрәт. Мөфти киләчәктә галимнәр арасында Матуриди тәфсирләренә алынучылар булачагына өмет белдерде.

«Матуриди тәфсиренең соңгы басмасы 17 томнан тора. Безнең арада, кулланырга җайлы булсын өчен, 3 томнан торган тәфсирләр басмасын әзерли алачак галимнәр бардыр, дип өметләнәм», – диде Камил хәзрәт.

Конференциядә катнашучылар ММЧ аша мөселманнар турында ялган стереотиплар таралуга бәйле вәзгыять, әйдәп баручы җитештерүчеләрнең кинопродукцияләрендә мөселманнарның тискәре образын мәҗбүриләп тагу кампаниясе, Көнбатыш геосәясәт үзәкләренең мәнфәгатьләренә таянып эш йөрткән радикаль агымнарның җимергеч эшчәнлеге һәм мөселманнарның тискәре образын тудырудагы роле хакында фикер алыштылар.

Искәртеп үтик: чараны ТР Изге Коръәнне һәм Пакъ Сөннәтне өйрәнү үзәге, ТР мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә, «Россия – ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме чараларын гамәлгә ашыру кысаларында оештырды.

■ **dumrt.ru**

# VII Якупов укулары

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә VII Якупов укулары үтте. Мәшһүр дин әһеле дөньяга килгән сентябрь аенда Татарстанның һәм Россиянең төрле төбәкләреннән килгән мөселман зыялыларының Вәлиулла хәзрәт Якуповны искә алулары матур традициягә әверелде. Быелгы укуларда катнашучылар да аның күпкырлы эшчәнлеген барлады, мирасын киләчәк буыннарга тапшыру юллары хакында фикерләште, дин, милләт өчен җан аткан шәхеснең ватанпәрвәрлегенә, кыюлыгына, ару-талуны белмичә фидакарьләрчә хезмәт итүенә сокланууларын белдерде. Җиденче тапкыр үткәрелгән укуларда Татарстан дини уку йортларының алдынгы шәкертләренә республикабыз мөфтиенең махсус стипендиясен тапшыру һәм Вәлиулла хәзрәт үзе нигез салган «Таян Аллага!» әдәби әсәрләр конкурсында җиңүчеләрне бүләкләп үтү нур өстенә нур булды. Исегезгә төшерәбез, быелның 4 сентябрендә В.Якуповның тууына 55 ел тулды.

Конференция эшендә Валиулла хәзрәтнең хезмәттәшләре, дуслары, остазлары, шәкертләре, фикердәшләре катнашты. Араларында Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөдире урынбасарлары Зөлфәт хәзрәт Габдуллин, Наил хәзрәт Яруллин, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Татарстан Республикасы Президенты эчке сәясәт департаментының дини оешмалар белән элемтә идарәсе белгече Айнур Солтанов бар иде.

Конференция Коръән укып, Вәлиулла хәзрәт Якуповның рухына дога кылудан башланды. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөдире урынбасары Зөлфәт хәзрәт Габдуллин укуларны ачып җибәрде һәм аны алып барды: «Вәлиулла хәзрәт кебек атаклы, зыялы, милләтпәрвәр шәхесләребезне киләчәк буыннар танысын, белсен, хөрмәтләсен өчен, шәкертләребезнең аңына сеңдерергә кирәк. Шул максаттан, бүген мәдрәсәбез укучылары һәм республикабызның алдынгы шәкертләре катнашында үз эшчәнлеген Вәлиулла хәзрәт тырышлыгы белән башлап җибәргән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә җыелдык. Аллаһы Тәгалә эшләребезне күркәм кылсын, динебез юлында армый-талмый хезмәт итәргә язсын», – дип теләкләрен җиткерде һәм чыгыш ясар өчен сүзне В.Якупов белән озак еллар хезмәт иткән, хәзер Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары булып эшләүче Рөстәм хәзрәт Вәлиуллинга бирде. Ул үз чиратында Вәлиулла хәзрәтнең бик авыр чорда эшләвен ассызыклады, милли үзаң уянган чорда дингә кереп китүдә милли аңның зур йогынты ясавы турында әйтте.

ТР Президенты Аппараты вәкиле Айнур Солтанов киләчәктә Вәлиулла хәзрәтнең тулы хезмәтләре җыелмасыннан торган китап чыгару тәкъдимен җиткерде.

Фәнни-гамәли конференциядә «Таян Аллага!» әдәби конкурсы җиңүчеләрен Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов тәбрикләде. Быелгы конкурста төп җиңүче булып Алинә Бикмуллина танылды.

■ **dumrt.ru**

## Идәндәге яки келәмдәге тузан белән тәяммум алырга ярыймы?



*Сорау:* **Кеше шәһәр фатирында яши ди, әгәр су бетеп, чакрым ярым ераклыкта су табып булмаса, яки кеше авыру булып, тәһарәт алу мөмкинлеге булмаса, аңа идәннән, келәмнән яки урын өстеннән тәяммум алырга ярыймы?**

*Җавап:* 1,609 м ераклыкта су табылмаса яки авыруы сәбәпле кеше тәһарәт ала алмаса, аңа тәяммум алырга рөхсәт ителә. Әмма тәяммум бары тик ком, ташлар, туфрак һәм тузан белән генә алына. Әгәр келәм яки идәндә тузан бар һәм бу урын нәҗестән пакь икән, кулларны идәнгә яки келәмгә сугып, тәяммум алырга була. Ә авыру кешегә тәяммумны урыныннан тормыйча, урын өстендәге тузан белән (әгәр яткан урыны нәҗестән пакь булса) алырга мөмкин. Моңа дәлил «Әл-Фәтәва Әл-Һиндия» китабында (1 том, 27 бит) һәм «Раддул-Мохтар»да (1 том, 171 бит) китерелә.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин**

## Беренче хатынга икенчесе хакында әйтү мәҗбүриме?

*Сорау:* **Әгәр мөселман икенче хатын алырга теләсә, аның беренче хатыны бу хакта белергә тиешме? Әллә беренче хатын гомумән икенчесе турында белмәсә дә ярыймы? Бу очракта ир-ат хатыннары арасында тигезлекне ничек саклар (төннәрне ничек тигез итеп бүләчәк)?**

*Җавап:* Беренче сорауга килгәндә, бу темага караган аять һәм хәдисләрдә ир-ат беренче хатынына икенче хатын алуы турында хәбәр итәргә тиеш яки рөхсәт алырга тиеш, дигән боерык юк. Әмма, әгәр никах вакытында, ике як арасында беренче хатын рөхсәтеннән башка ир икенче хатын ала алмый, дигән килешү булса, һәм ир-ат бу шартны кабул иткән булса, ул беренче хатынының рөхсәтеннән башка икенчене алса, беренче хатын үзенә талак алырга һәм аннан аерылып китәргә хокуклы. Тарихта шундый вакыйга билгеле: Бохара шәһәре хатын-кызлары галимнәргә ирләренә зарланырга килгән. Ирләре аларны тәэмин итмәгән; кул күтәргән; хатыннар риза булмый торып, аларны башка шәһәрләргә алып киткән; икенче хатын итеп яшь кызларны алып, беренчеләренә игътибар итмәгән. Шуннан соң Бохара галимнәре, хатын-кызларның хокуклары саклансын өчен, никах укылганда дүрт шарт кертә:

– хатынны ай календаре буенча алты айдан да озаграк тәэмин итмәскә ярамый;

– шәригатьтә рөхсәт ителгән очраклардан кала, кул күтәрмәскә;

– хатынны аның әти-әниесе яшәгән шәһәрдән алып китмәскә;

– беренче хатынның рөхсәтеннән башка икенче хатын алмаска.

Һәм бу дүрт шартның берсе генә булса да үтәлмәсә, хатын-кызның сайлау мөмкинлеге барлыкка килә: ул йә үзен-үзе аера ала, йә хәле белән ризалашып, ире белән кала.

Икенче сорауга килгәндә, Изге Коръәндә Аллаһы Тәгалә: **«Әгәр гаделлек кыла алмабыз дип курыксагыз, фәкать берне генә никахлагыз»**, – дип әйтә.

Шулай ук Пәйгамбәребез галәйһис-сәламнең хәдисендә: «Кемнеңдер ике хатыны булып, ул аларга тигез карамаса, Кыямәт көнендә ул икенче яртысы артыннан сөйрәлеп барган хәлдә кубарылачак (параличланган кеше сыман)», – диелә.

(...) Мондый очракта кеше беренче хатынына икенчесе турында әйтергә мәҗбүр булачак, чөнки икенче хатыны янында булганда өйдә булмавын аңлатырга кирәк.

Ә әгәр сезне минем шәхси фикерем кызыксындырса, болай дим: «Ике фронтың булганчы, бер ышанычлы тылың булсын».

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин**

## Нәфел намазлар нинди була һәм кайчан укыла?

*Җавап:* Нәфел намазлар ике төрле була:

1. Билгеле бер вакытта укыла торган нәфелләр. Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһис-сәлам бу намазларны билгеле бер вакытта укыган һәм аларның рәкәгатьләр саны да билгеле. Мисал өчен: тәһәҗҗед – төннең икенче яртысыннан таң атканчыга кадәр, 2 рәкәгатьтән алып 10га кадәр укыла; ишрак – кояш чыкканнан соң ярты сәгать үткәч, ике рәкәгать итеп укыла; духа – ишрактан соң зәвәл вакытына кадәр, 2дән алып 8 рәкәгатькә кадәр укыла; әввәбин – ахшамнан соң 2 рәкәгатьтән 6га кадәр укыла. Бу нәфел намазларны шушы билгеләнгән вакытларында укырга кирәк.

2. Теләсә ничә җөп санлы рәкәгать һәм теләсә кайсы вакытта укырга яраган нәфел намазлар. Әмма аларны кояш чыкканда, зәвәл вакытында, кояш баеганда, таң беленгәннән башлап кояш чыкканчыга кадәр (иртәнге намаз вакыты), икенде намазын укыганнан соң кояш баеп беткәнчегә кадәр, хөтбә сөйләнелгән вакытта укырга ярамый.

Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин**

## Мәчеттә әдәп кагыйдәләре

*Сорау:* **Мәчеттә үзеңне тоту кагыйдәләре бармы? Аларны барысы да белсен өчен, мәчеттә элеп куярга буламы?**

*Җавап:* Факиһ Әбү Ләйс Әс-Сәмәрканди (Аллаһ аны рәхмәтеннән ташламасын) «Тәнбиһүл-гафилин» китабында мәчеткә карата 15 төрле күркәм гамәл китерә:

1. Мәчеткә кергәндә, әгәр мәчеттә утыручы кешеләр дәрес яки зикер белән мәшгуль булмаса, аларны сәламләү. Әгәр мәчеттә беркем дә булмаса яки анда утыручылар намаз укыса (зикер әйтсә), керүчегә: «Әс-сәламү галәйнә мир-Раббинә вә галә гыйбәдилләһис-салихин», – дип әйтергә кирәк.

Тәрҗемәсе: «Раббыбыздан безгә һәм Аның барча тугры колларына сәлам».

2. Утырыр алдыннан ике рәкәгать мәчетне сәламләү намазы уку.
3. Сату-алу эшләре алып бармау.
4. Корал чыгармау.
5. Югалткан кешеңне эзләмәү.
6. Зикер әйтүдән кала, тавышны күтәрмәү.
7. Дөньяви хакында сөйләшмәү.
8. Утыручылар аша атлап үтмәү.
9. Урын өчен тарткалашмау.
10. Намазда рәттәге кешеләрне кысырыкламау, уңайсызлык китермәү.
11. Намаз укучылар алдыннан узмау.
12. Төкермәү.
13. Бармак шартлатмау.
14. Мәчетне кечкенә балалар, үз акылында булмаган авыру кешеләрнең нәҗесләреннән пакьләү
15. Аллаһы Тәгаләне күбрәк зекер итү.

«Әл-Гараиб» китабында шулар ук китерелә.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин**



# Яхшылыкка өндәү һәм тыйганнан тыю

Ислам динендә савап-гөнаһ, изгелек-начарлык, җәннәт-җәһәннәм кебек капма-каршы булган сүзләрне еш очратырга була. Һәм, гадәттә, әгәр дә берсе турында яхшы яктан сөйләнелсә, икенчесе турында кисәтү рәвешендә сөйләнелә. Әгәр кеше изгелек кылса, савап була, әгәр яман гамәл кылса, гөнаһ. Шуңа күрә, савапны җәннәткә илтә торган изге гамәлләрне кылырга чакырырга, ә җәһәннәмгә илтә торган яман эшләрдән тыярга тырышырга кирәк. Асылда, Аллаһы Тәгалә йөкләгән һәр гыйбадәт кешене бозыклыктан, пычраклыктан ерагайта һәм Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә, мәгъфирәтенә якынайта. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Мөэмин ирләр вә мөэминә хатыннар бер-берсенә дуслар вә ярдәмчеләр: алар кешеләрне иманга, дингә вә яхшылыкка өндәрләр һәм начарлыклардан тыярлар...**

«Тәүбә», 9:71

Калган өммәтләрдән аермалы сыйфат та шушы. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Алар үзләре кыла торган бозык эшләрдән, батыл игътикатлардан бер-берсен тыймадылар, нинди яманлыктыр аларның эшләгән эшләре».**

«Мәидә / Аш Ялугы», 5:79

Ике аятьтән дә хәерле, яхшы эшкә чакыру һәм начарлыклардан тыю мөэмин мөселманнарның төп сыйфатларыннан икәнен белә алабыз. Шуңа күрә берәр мөселман үзенең кардәшенең хатасын күреп, аны төзәтергә җыена икән; яки аңа күркәм, изге гамәлләр турында сөйләп, аларны кылырга өнди икән – бу алар арасында дошманлык хисләре тудырырга тиеш түгел. Киресенчә, андый кешеләрнең сүзләренә колак салырга, үзеңдә булган хатаны төзәтү өстендә эшләргә, изге гамәлләр санын арттырырга тырышырга кирәк. Мөхәммәд галәйһис-сәлам: «Мөэмин мөэминнең көзгесе», – дип әйткән. Димәк, кем дә булса килеп бездә булган берәр хатаны әйтсә, без аны кабул итәргә, аны бетерү өстендә эшләргә тиеш. Шулай ук үзебез дә берәр кардәшебездә нинди дә булса кимчелек күрсәк, аны аңа күркәм итеп җиткерергә тиешбез. Аятьтән күренгәнчә, бу гамәл – яхшылыкка чакыру һәм начарлыктан тыю – ирләр арасында да, хатын кызлар арасында да булырга тиеш.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам: «Сез җитмеш өммәт арасыннан соңгы өммәттер. Әмма Аллаһы Тәгалә каршында иң хәерле өммәт – сез!» – дип әйтте. Медальнең ике ягы бар, шуңа күрә, бу аятьнең тәфсирен дәвам итеп, шуны әйтеп була: кешеләрне яхшылыкка чакырып, начарлыктан тыйган өммәт – хәерле өммәт. Әмма бу эштән туктау белән, медальнең икенче ягы ачылачак. Кешеләр бер-берләренә нәрсәнең начар, нәрсәнең әйбәт икәнен сөйләмәсәләр, бу өммәтнең күркәмлеге югала башлаячак дигән сүз. Бу хәл галимнәр, алардан гыйлем алучылар, шул гамәлләре белән гамәл кылучылар булганда, беркайчан да булмаячак, чөнки исламның төп асылларының берсе – күркәм холык. Начарлыкны күреп тә, аны туктатмаган кешедә яхшы холык бар дип әйтергә бик авыр булыр иде. «Мөэмин – мөэминнең көзгесе», шулай булгач, үзенә кылган изге гамәлләрне кардәшендә дә күрергә тырышкан кеше, шулай ук күркәм өммәт әһеленнән саналачак.

Бу өммәткә мондый хөрмәт, иң беренче чиратта, әлбәттә, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам аркасында булды, чөнки ул бу дөньяга рәхмәт буларак җибәрелгән Аллаһы Тәгаләнең иң яраткан бәндәсе иде. Пәйгамбәребезгә Ул бер пәйгамбәргә дә индермәгән Коръәнне индерде. Имам Әхмәд тапшырган хәдистә болай дип әйтелә: «Пәйгамбәребез: «Миңа бер генә пәйгамбәргә дә бирелмәгән әйберләр бирелде», – дип әйткән. Сәхабәләр: «Нәрсә соң ул?» – дип сорагач, Мөхәммәд: «Миңа дошманнарның күңелләренә курку салу белән җиңү бирелде, миңа җирнең ачкычлары бирелде, мине Әхмәд дип атадылар. Бу җир минем өчен чиста булды (бөтен җир – мәчет, ягъни кайда гына булсаң да, нәҗес булмаган очракта, анда намаз кылып була) һәм минем өммәтем иң күркәм өммәт булып санала», – дип җавап кайтарган».

## Көч җитмәгәндә йөрәк белән шелтәләү

Мөселманның кулы һәм теле белән шелтәләргә көче җитмәсә, йөрәге белән шелтәләү аның өстеннән бурычны төшерә. Ибне Мәсгуд разыяллаһу ганһе: «Сезнең озак яшәгәнегез начарлыкны күреп, бернәрсә эшли алмаслык вакытка якын булачак. Ул эшнең йөрәгенә нәфрәтле булганын бер Аллаһ кына беләчәк», – дигән. Имам Ән-Нәвәви «40 хәдис» китабында болай дип яза: «Көчсезлек» дигәндә, кешенең үзенә яки малына зарар килер һәм ул моңа түзә алмас, дип куркуы күз алдында тотыла. Әгәр ул үзе белән шундый хәл булуына тулысынча ышанмый икән, йөрәк белән инкяр итү аны бу бурычтан азат итми. Ул, һичшиксез, кулы яки теле белән шелтә белдерергә тиеш булачак.

> Расүлебез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): “Дин – ул нәсыйхәт”, – дигән. Сәхабәләре: “Кемгә карата?” – дип сораганнар. Ул: “Аллаһка, Аның китабына, Аның Расүленә, мөселманнарның җитәкчеләренә һәм гади мөселманнарга”, – дип җавап кайтарган.

Мөселман бер начар нәрсә күрсә яки аның турында ишетсә, аны төзәтү ул кешегә фарыз була. Шулай ук бер төркем кеше күреп тә, алардан бер генә кеше төзәтә алган очракта, ул аны төзәтергә тиеш. Төзәтмәсә, өстенә гөнаһ алачак».

## Начарлыктан тыюның әһәмияте

Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам бу эшнең әһәмиятлелегенә басым ясап мондый мисал китерә: «Аллаһның чикләре бозылмауны саклаучылар һәм шул чикләрне үтәүчеләрне корабта урын алу өчен шобага салучыларга тиңләп була. Шул шобага нәтиҗәсендә берсе югары катка, икенчеләре түбән катка урнашкан. Астагылар су алырга теләгәндә аларга палубада урнашучылар аркылы узарга туры килгән. Ахыр чиктә алар: «Бәлки өстәгеләрне мәшәкатьләмәс өчен безгә кораб төбендә тишек тишеп, шуннан су алырга кирәктер?» – дигәннәр. Әгәр өстәгеләр астагыларны шул хәлдә калдырсалар һәм тегеләре үз теләгәннәрен эшләсәләр, барысы да һәлак булачак. Алар тегеләрне кулларыннан тотып алсалар, үзләре дә исән калачаклар һәм башкаларны да коткарачаклар».

Яхшылыкка өндәү һәм начарлыктан тыю берничә шартка да бәйле. Беренчедән, гыйльми нигез булу. Икенчедән, чакырган вакытта да, тыйган вакытта да йомшак булу. Өченчедән, сабыр булу. Бу өч компонент бик кирәк. Әгәр кеше үзе нәрсәгә чакырганын белмәсә (гөнаһлы әйбергә чакырадыр бәлки), аның үзенә дә гөнаһ булуы бар. Шулай ук ул йомшак булмаса, кешеләр аны гомумән тыңламаслар иде. Шулай ук, иң авыр әйберләрнең берсе – сабыр булу. Әмма кемгә дә булса берәр нәрсәне тыйганнан соң, ул кеше аны шунда ук ташлар дип өмет итәргә ярамый. Һәм яхшылыкка өндәгәннән соң да, ул кеше аны шунда ук эшли башлар дип тә уйларга ярамый. Ничәдер көн, бәлки айлар, бәлки еллар үтүе дә бар, шуңа күрә, әлбәттә, сабырлыкның запасы күп булырга тиеш.

## Файдалы киңәшләр

– әгәр дә хата бер генә кешедә икән һәм ул аңа гына караса, аның үзе янына гына барып, хатасын төзәтергә кирәк;

– әгәр хата бер кешедә генә, әмма ул җәмгыятькә дә карый икән, бу хата турында җәмгыятькә дә әйтергә кирәк. Әмма хата кылган кешенең исемен һич әйтергә ярамый. Монда халыкка проблема барлыгы турында гына әйтергә кирәклеге ассызыклана;

– шулай ук хата бер халыкта икән, аларга да йомшак кына, файдалы итеп әйтергә тырышырга кирәк.

– «Үзем кылмыйм», – дип, дәшмичә калырга кирәкми. Бәлки син үзең әзер дә түгелсеңдер. Әмма кемгәдер әйтеп, ул кеше шуны эшли башлагач, син үзең дә аңа ияреп шул изге гамәлләр кылучылар рәтенә керә аласың;

– яхшылыкка чакыру һәм начарлыктан тыю турында калганнарга да сөйләргә һәм аның турында сөйләнгән җыелышта булмаган кешеләргә җиткерүне сорарга кирәк.

Аллаһы Тәгалә барыбызга да Аның динендә нык торырга, дусларыбызга, туганнарыбызга, ата-аналарыбызга диннең матурлыгын, күркәмлеген җиткерергә, аларны бозык гамәлләрдән кисәтергә, саклап калырга көч, ярдәм вә җиңеллек бирсә иде. Әмин!

■ *Хәсинә Гыйззәт*

# «Сез иң галим кеше икәнсез»

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Галим бул (гыйлемгә өйрәтүче), йә гыйлемне өйрәнүче бул, йә гыйлемне тыңлаучы, йә гыйлемне яратучы бул, әмма бишенчесе булма, һәлак булырсың», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез башта ук гыйлемне яратыгыз, дип әйтә ала иде. Әмма ул беренче урынга иң бөек дәрәҗәне – гыйлем иясе булуны куя. Янә Пәйгамбәребез: «Ислам дине галиме булыгыз», – димәде. Һәм, әлбәттә, Исламда шушы фәннәрне генә укыгыз, дигән сүзе дә булмады. Ни өчен? Әбү Дәрда разыйаллаһу ганһү: «Пәйгамбәребез безгә барлык фәннәр турында да сөйләде һәм кошларның һавада ничек очуларына кадәр аңлатып бирде», – дип әйткән. Һавада кошның ни рәвешле очуы белән, намазны ни рәвешле уку арасында аерма күп тә соң. Берсе дини, берсе дөньяви гыйлем булып санала. Әмма бу әйбергә Пәйгамбәребез дә басым ясаган.

Кабаттан хәдискә әйләнеп кайтыйк: «гыйлемне өйрәтүче галим бул». Ә укытучы булу җиңелме? Алган гыйлемнәрне бүтән кеше аңларлык итеп аңлата белү һәр кешегә дә бирелгәнме соң? Тиздән илебез укытучылар көнен билгеләп үтә. Бу мәктәп, урта һөнәри техникумнар, университет, мәчет-мәдрәсәләрдәге укытучыларның барысына да кагыла торган бәйрәм. Әйе, без барыбыз да укытучылар: эти-әни, апалар сеңелләрен укыта, үзебез дә берәр хәдис ишетүгә аны икенче кешегә җиткерәбез. Әмма дәүләт бу көнне рәсми рәвештә бу һөнәрне үзләштереп, үзләренең гомерләрен шушы гамәлгә багышлаган кешеләр өчен бәйрәм итеп билгеләгән.

Бүгенге көндә мәктәптә укыган балаларыбызга: «Укытучыңны тыңла, аны ихтирам ит», – дип көн саен әйтсәк тә аз. Без өйдә ике-өч баланы көч-хәл белән генә тыңлата алабыз. Ә мәктәп укытучысы таныш булмаган 10нан алып 20, 30 баланы бер сыйныфта үзенә каратып утырта ала. Аларга үзендә булган гыйлемне бирә, әдәп-әхлак серләренә төшендерә.

Кадерле мөселман кардәшләр, без үзебезнең балабызны мәдрәсәгә биргәндә, анда укыячак бөтен бала да дини гаиләдә тәрбияләнгән икәнен аңлап киләбез. Ә мәктәптә төрле бала була. Алар төрлечә тәрбияләнгән, шуңа күрә сыйныфта үз-үзләрен тотышлары да аерылып торачак. Моннан чыгып, мәктәп укытучысына дәрестә белем бирүдән тыш, тагын бик күп төрле проблемаларны чишәргә туры килә.



Әгәр безнең балаларыбыз үзләренең укытучыларын хөрмәтләргә өйрәнсәләр (мәктәп, мәдрәсә һ.б. уку йортындагы), аларның белем алу процессы да җиңеләер иде һәм Аллаһы Тәгалә ул гыйлемнең бәрәкәтен дә бирер иде. Укучы үзенең укытучысын авыру кеше табибны тыңлаган кебек тыңларга тиеш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд: «Олы кешеләрне хөрмәтләмәгән, кече яшьтәгеләргә мәрхәмәтле булмаган һәм гыйлем ияләренә аларның хакларын бирмәгән кеше безнең өммәттән түгел», – дип әйткән.

Имам Гали разыйаллаһу ганһү укучыларга укытучыларга карата нинди булырга кирәклеген түбәндәге киңәш рәвешендә әйтә: Сиңа иң башта бөтен кешеләрне сәламләп, аннан соң укытучының үзенә аерым сәлам әйтү кирәк. Син аның серләрен сөйләмәскә, дәрестә кулларыңны селкеп утырмаска, аңа күз кысмаска, аңа күп сораулар бирмәскә, ул җавап кайтарганда аның сөйләменә кушылмаска тиеш, ... әгәр аңа берәр нәрсә кирәк булса, калганнар аны эшләгәнче, аны үзең эшләргә ашыгырга кирәк».

Шулай ук укучы үзенең укытучысы өчен хәерле догалар кылырга, аның хәлен белеп торырга онытмаска тиеш. Мәктәптә 11 ел, югары уку йортларында, мәдрәсәләрдә 4 ел буе укытучылар безгә эти-әниләребезне алыштыралар. Алар бирә алмаган, яисә биреп бетермәгән белемне, тәрбияне бирәләр, җәмгыятьтә үзебезнең урыныбызны табарга булышалар. Имам Шафигый рәхмәтуллаһи галәйһи: «Мин имам Мәлик каршында китап укыганда, аның битләрен имамга ишетелмәслек итеп тавышсыз ача идем», – дип әйткән. Укытучыга карата хөрмәт күрсәтү безнең әдәп-әхлагыбызны күрсәтә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам: «Беркем дә әдәп-әхлаксыз югары дәрәҗәгә күтәрелә алмады, ә әдәп-әхлакны калдырган кешеләр аска таба тәгәрәделәр», – дип әйткән. Безнең җирлегебездә Әбү Хәнифә нигез салган мәзһәб тотыла. Әбү Хәнифә дигәч, зур галим күз алдына баса. Әмма Әбү Хәнифә гыйлем алган остазларын онытмаган. Ул берсендә: «Мин аягымны бу якка сузып йоклый алмыйм. Ул якта минем остазым Хәммад яши», – дип әйткән.

Бервакыт Габдуллаһ бине Әл-Мөбарәктән: «Әгәр Аллаһы Тәгалә сиңа вәхи иңдереп бүген үләчәгеңне хәбәр итсә, ни эшләр идең?» – дип сорыйлар. Ул: «Мин гыйлем алу белән шөгыльләнер идем, чөнки Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезгә дөнья нигъмәтләрен бирде, әмма аны арттырырга кушмады. Шулай ук Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезгә гыйлем бирде һәм аны арттырып торырга кушты. Аллаһы Тәгалә аны Коръәндә боерды: **«Дәхи, Раббым белемемне арттыр, диген!»** («Та Һа», 20:114) – дип җавап кайтарды.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд: «Аллаһы Тәгалә гыйлемне киметми, Ул башка нәрсәләрне киметә. Әмма Ул гыйлемне галимнәрне бетереп юкка чыгара», – дип әйткән.

Шулай ук ул: «Гыйлем бирүчене кимсеткән кешене Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә түбәнсетер», – дип әйтте.

Габдуллаһ бине Гомәр болай дип әйткән: «Бөтен кешеләр дә авыру. Әмма галимнәр – дәвалаучылар. Савыгырга теләгән кеше аларга якын булсын. Аларга карау – гыйбадәт, алар белән бергә йөрү – дәрәҗә, алар белән бер өстәл артына утырып ашау – дәвалану, чөнки алар белән бергә булган кешеләр беркайчан да кайгы-хәсрәткә бирелмәсләр. Аларны яклаган кеше үзе яклау астында булыр. Аларга каршы чыккан кеше үзе бәхетсез булыр».

Кадерле җәмәгать! Аллаһы Тәгалә кешеләрне тән ягыннан, дәрәҗә ягыннан, акыл ягыннан, байлык ягыннан төрле итеп яраткан. Кемгәдер гыйлемне күбрәк, кемгәдер азрак биргән. Балаларга гыйлем алуны җиңел кылган, чөнки аларның башларында кирәкмәгән мәгълүмат әлегә юк. Ә кем үзен аз беләм дип саный, алар һәрвакыт белгән кешеләрдән сорый алалар: **«Белмәгән һәрнәрсәгезне белгән кешеләрдән сорагыз!»** («Умарта Кортлары», 16:43).

Ә шул белгән кешеләр турында Аллаһы Тәгалә икенче аятьтә әйтә: **«Әйт: «Белүчеләр белән белмәүчеләр бер дәрәҗәдә булырлармы?»** («Зүмәра / Халык Төркеме», 39:9).

Ягъни гыйлем ияләре белән гыйлемсезләр Аллаһ каршында төрле дәрәҗәдәге кешеләр. Шулай булгач, укучы үзенең остазы белән ихтирам күрсәтеп аралашырга тиеш.

Кадерле җәмәгать, бүген без гыйлем, аның дөньяви һәм дини булуына карамастан, бер үк әйбер – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен ысул икәнен, укытучылар, аларның авыр вазифалары турында, үзенең остазыңа карата ихтирамлы булырга кирәклеге турында бик кыска гына сөйләшеп алдык. Аллаһы Тәгалә безне галим, йә аны өйрәнүче, йә аны тыңлаучы, йә гыйлемне һәм гыйлем өйрәтүчеләрне, галимнәрне яратучылардан кылса иде. Барча укытучыларны аларның бәйрәмнәре белән котларга рөхсәт итегез. Без һәрвакыт аларга догада булыйк, исәннәренең кадерен белеп, аларның хәл-әхвәлләрен белешеп торыйк. Аллаһы Тәгалә барчаларыбызга да хәерле гомер, сәламәтлек насыйп әйләсен.

■ «Шура» №21

# Зәкәт – Раббыбызга малыбыз белән гыйбадәт кылу

**Зәкәт – хәлле мөселман кешенең һәр елны үз малының 1/40 өлешен ярлылар файдасына бирүен аңлата. Намаз белән бергә зәкәт Коръәндә 37 тапкыр искә алына. Әлеге факт аның Ислам динендә тоткан мөһим ролен күрсәтә.**



## Кемнәр зәкәт түләргә бурычлы

Түбәндәге шартларга туры килгән кешеләр зәкәт түли:

1. Мөселман булган.
2. Үз акылында булган.
3. Балигъ булган.
4. Азат булган.
5. Хәлле булган, ягъни нисаб күләмендә малы яки акчасы булган (көнлек ихтыяҗларыннан артканы).

Түбәндәге шартларга туры килгән мал-мөлкәтнең яисә акчаларның бер өлеше зәкәт итеп түләнә:

1. Нисаб күләмендә булу, ягъни 85 грамм алтынга яки 595 грамм көмешкә тиң күләмдә.
2. Ай календаре буенча санаганда тулы ел буе әлеге мал-мөлкәткә хуҗа булу.
3. Мал-мөлкәтнең арта баруы.

***Нисаб*** – динебез куйган байлык үлчәме. Шәригать куйган дини канунга күрә, нисаб күләмендәге мал-мөлкәте яки акчасы булган кеше хәлле булып санала. Бу хисапка бурычка алынмаган һәм үз ихтыяҗыңнан арткан мал-мөлкәт кенә керә. Алтын буенча, быел нисаб күләме 200 000 сум дип билгеләнде.

## Зәкәт кемгә түләнә

Коръәни Кәримдә әйтелгән: **«Аллаһның бер тәкъдире буларак, сәдакаләр фәкыйрьләргә, мескеннәргә, сәдакаларны җыеп тараткан кешеләргә, күңелләре дингә җәлеп ителер кешеләргә, колларны азат итәргә, бурычка төшкәннәргә, Аллаһ юлындагыларга һәм юлда калучыларга сарыф ителәчәктер. Аллаһ – Галим, Хәкимдер».**

«Тәүбә», 9:60

**Зәкәт түбәндә китерелгән сигез категория кешегә түләнә:**

1. Фәкыйрьләргә – дин күзлегеннән караганда бай булмаган, мал-мөлкәте нисаб күләменнән азрак кешеләргә; хәтта алар үзләре эшләп таба алсалар да, аларга барыбер зәкәт бирергә була.
2. Мескеннәргә – бернәрсәсе булмаган кешеләргә.
3. Зәкәт җыеп, башкаларга тарату эше белән шөгыльләнүчеләргә.
4. Исламны әле генә кабул итүчеләргә, аларның Аллаһ диненә булган мәхәббәтләрен арттырыр өчен.
5. Үзләрен коллыктан азат итәр өчен колларга.
6. Бирәчәк бурычлары бөтен мал-мөлкәтеннән күбрәк булганнарга.
7. Аллаһ юлында булганнарга. Кайбер фәкыйһләрнең фикеренчә, зәкәтне хаҗ кылырга теләүче ярлыларга яки гыйлем алу юлында булганнарга бирергә ярый.
8. Юлчыларга, (хәтта үз ватаннарында аларның нисаб күләмендә мал-мөлкәте булса да) Үз мәмләкәтләренә кайтыр өчен акчасыз калган очракта, аларга зәкәт өйләренә кайтып җитә алсын өчен бирелә.

**Зәкәт биргән вакытта түбәндәге тәртиптә өстенлек бирелә:**

1. Бертуган ир һәм кыз кардәшләр, аннан соң – аларның балалары.
2. Ата һәм ана ягыннан алар белән бертуган абыйлар һәм апалар.
3. Калган туганнар.
4. Күршеләр.
5. Үз районында яшәгән фәкыйрьләр.
6. Үз шәһәрендә яшәгән фәкыйрьләр.

Зәкәт итеп биргән малың нәкъ тә мохтаҗ булганнарның кулына ирешсен өчен кирәкле чарасын күрергә кирәк, бу малның гөнаһ эшләүгә яки исраф кылуга сәбәпче булуына юл куймаска кирәк.

**Түбәндәге кешеләргә зәкәт бирелми:**

1. Әти-әни, әби-бабайга.
2. Улың белән кызыңа һәм аларның нәселеннән булганнарга.
3. Хәлле кешеләргә.
4. Мөселман булмаганнарга.
5. Иреңә яки хатыныңа.
6. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең гаиләсенә һәм аның нәселенә.
7. Җиде яшьтән кечерәк балаларга һәм психик авыруларга.

## Күзгә уңыштан гошер сәдакасын түләргә онытмыйк

Яңгыр яки елга суы белән үскән ашлыклардан, җимешләрдән, печәннән һәм балдан бирелә торган зәкәт «гошер» дип атала. Шул нигъмәтләргә ия булган кешегә елга бер мәртәбә аның уннан бер өлешен казна хәзинәсенә яки фәкыйрьләргә бирү – фарыз.

Гошер малларының нисабы юк: никадәр булса, шулкадәренең уннан бер өлеше гошер итеп бирелә. Игү, уру һәм чәчүлекне карау чыгымнары исәпләнми.

Гошер бирү өчен балигъ, акыллы һәм бай булу шарт түгел. Сабый, акылга зәгыйфь һәм фәкыйрь кешеләрнең ашлыкларыннан да гошер чыгарыла.

Яңгыр күп яумый торган җирләрдә, чыгыр һәм чиләк белән сугарылган ашлыклардан камил гошер бирелми, ә гошернең яртысы гына, ягъни егермедән бер өлеше генә бирелә.

Гошер дә зәкәт бирелә торган фәкыйрь кешеләргә генә тапшырыла.

■ **«Ислам дине нигезләре», «Гыйбадәте Исламия» китапларыннан**

# Зәкәткә кагылышлы фәтвалар

## Зәкәтне нисаб күләменнән артыграк итеп түләргә ярыймы

***Сорау:* Ярлы кешегә зәкәтне нисаб күләменнән артыграк итеп бирергә ярыймы?**

***Җавап:*** Нисаб күләме 100 000 сум, дип күз алдына китерик. Бай кеше бер үк мохтаҗ кешегә башта 50 000 сум, күпмедер вакыт узганнан соң тагы 40 000 сум, янә күпмедер вакыт үткәч 60 000 сум бирде, ди. Ягъни барлыгы ул 150 000 сум биргән. Бу рөхсәт ителә, чөнки түләүләр төрле вакытта һәм аларның күләмнәре нисабтан кимрәк иде. Бай кеше мохтаҗга соңгы 60 000 түләгәндә дә, ул кеше әле фәкыйрь санала иде, чөнки аның нисабы юк иде. Шул рәвешле, бу бар түләүләр дә зәкәттән санала.

Хәзер башка очракны карап китик. Нисаб күләме шулай ук 100 000 дип күз алдына китерик, әмма бу юлы бай кеше мохтаҗга 500 000 сум түли. Башта ул аңа берьюлы 200 000 сум, аннан соң өчәр тапкыр 100 000 бирә, ди. Бу очракта зәкәт булып беренче бирелгән 200 000 сум гына саналачак, чөнки аларны алганнан соң, мохтаҗ кеше фәкыйрь булып саналмый башлады, ул алган акчалар нисаб күләменнән артып китте.

Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

## Башка кешенең бурычын түләү зәкәт була аламы?

**Сорау: Зәкәт бирү нияте белән башка кешенең бурычын түләргә ярыймы?**

***Җавап:*** Башка кешенең бурычын капларга теләсәгез, аңа: «Мин зәкәт түләп, синең бурычыңны капларга телим», – дип әйтергә тиешсез. Әҗәтле кеше: «Бурычымны түлә», – дип ризалашса, сез акча түләгәннән соң зәкәт түләгән дә, кешенең бурычын каплаган булып та саналачаксыз («Радд әл-Мохтар»).

Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

## Зәкәт бай кешегә бирелсә

**Сорау: Мин зәкәт түләгән кешенең фәкыйрь булмавы ачыкланды. Миңа хәзер нишләргә?**

***Җавап:*** Бу мәсьәлә буенча берничә төрле фикер булса да, бу зәкәт дөрес һәм аны яңадан түләргә кирәкми, дигән фикер гомум кабул ителгән булып санала (имам Мәүсыли, «Әл-Ихтыяр»).

Бай кеше аңа бирелгән акчаның зәкәт булуын белмәскә дә мөмкин, әмма ул акчаларның зәкәт икәнен белеп алганда, моның өчен җавап тотачагын аңларга тиеш.

Янә шуны да искәртәсе килә: зәкәт түләүче кеше ниятен кычкырып әйтмәсә дә ярый, калебтә ниятләү җитә.

Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие**

# Татарстан мөфтияте һәм «Хозур ТВ» Россиядә мөселман социаль ТВ-рекламасы киңлеген булдыра һәм үзләштерә

Казанда XIV Казан халыкара мөселман киносы фестивале кысаларында ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур ТВ» телекомпаниясеннән кыска метражлы фильмнар премьерасы узды.

Презентациядә хәзерге җәмгыятьнең гомумкешелек кыйммәтләренә каршы килгән әхлакый өстенлекләре, шулай ук ислам турындагы стереотиплар темасына төшерелгән фильмнар циклыннан берничә ролик күрсәтелде. Барлыгы шундый 30 ролик төшерелгән.



Чарада Россиядә мөселман социаль телевизион рекламасының тенденцияләре, проблемалары һәм үсеш дәрәҗәсе, шулай ук аның сыйфаты, роле һәм нәтиҗәлелеге турында фикер алыштылар. Фикер алышуда һәм «Хозур ТВ» телекомпаниясенең кыска метражлы фильмнарын тәкъдим итүдә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм әйдәп баручы мөселман блогерлары, шулай ук танылган Россия актёры, «Ласковый май», «Экипаж» һәм башка фильмнарда төшкән Сергей Романович катнашты.

Сергей Романович үзенең исламга килү һәм аны кабул итү тәҗрибәсе белән уртаклашты, шулай ук иҗтимагый кыйммәтләрне формалаштыруда мөселман телевидениесенең ролен ассызыклады.

– Без үзебезнең дәгъват эшчәнлеген хәзерге заман таләпләренә һәм мөмкинлекләренә таянып камилләштерергә һәм киңәйтергә тиеш, – диде йомгаклау сүзендә мөфти хәзрәт. – Әгәр дә яшьләр мәгълүматны интернеттан алалар икән, димәк, без дә бу челтәрдә эшләргә тиеш. Әгәр дә телевидение җәмгыятьтә һаман да популяр ММЧ булып кала бирә икән, без аңа сыйфатлы, эчтәлекле контент тәкъдим итәргә тиеш. Шушы роликлар дәгъват эшчәнлеген көчәйтер, дип өметләнәбез.

Социаль роликларны «Хозур ТВ» телекомпаниясе ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең җәмгыятьтә исламның традицион кыйммәтләрен пропагандалау буенча эшчәнлеге кысаларында әзерләде. ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин тарафыннан өстенлекле юнәлеш дип билгеләнгән әлеге эшчәнлекне «Хозур» нәшрият йорты тормышка ашыра. Татарстан мөселман өммәтенең рухи традицияләрен һәм мәдәниятен ныгыту юлында нәшрият берьюлы берничә юнәлештә эш башкара: дини әдәбият бастыру, мөфтиятнең Darul-Kutub.com электрон китапханәсен үстерү, басма, электрон, радио һәм телевизион мөселман гаммәви мәгълүмат чараларын эшләтү, интернет-проектларны гамәлгә ашыру.

«Хозур» нәшрият йортының ислам кыйммәтләрен пропагандалау буенча эшчәнлегенең шактый зур өлеше интернет киңлегендә алып барыла. Islam-Today.ru порталы Россиядә иң популяр һәм абруйлы ислам яңалыклары сайтларының берсе булып тора. Статистика нәтиҗәләре күрсәткәнчә, 2017 елда порталга керүчеләр саны 23 миллионга җиткән. Terrora-net.ru сайты да уңышлы эшләвен дәвам итә. Ул Татарстанда дини экстремизмга кагылышлы сорауларны тулысынча колачлаган бердәнбер интернет-мәйданчык булып кала бирә.

«Хозур» нәшрият йорты социаль челтәрләрдә экстремизмны профилактикалау буенча да актив эш алып бара. Хәзерге вакытта Интернетта шундый 11 төркем эшләп килә. Аларда 1000гә якын язма дөнья күрде. Тулаем язылучыларның саны исә 1 миллионга җитте. ТР мөселманнары Диния нәзарәте өчен иң мөһим пропаганда чарасы булып «Хозур ТВ» мөселман телеканалы хезмәт итә. Ул ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин башлангычы һәм «Таттелеком» ГАҖ ярдәме белән тормышка ашырылды. Телевидение Татарстан һәм Башкортстан республикалары территориясендә кабельле челтәрләрдә трансляцияләнә. Телеканалның төп максаты – ислам өлкәсендә агарту, рухи-әхлакый кыйммәтләрне популярлаштыру, җәмгыятьтә толерантлык тәрбияләү. Хәзерге вакытта телеканалның тапшырулар челтәрендә барлыгы 1537 программа трансляцияләнә. Телеканалның YouTube-версиясендә агымдагы елда 40 миллионнан артык карау теркәлгән.

■ **dumrt.ru**

# Татарстан Президенты үзенең Юлламасында «Хозур-ТВ»ны югары бәяләде

*Дәвамы. Башы 1 нче биттә*



Нигездә, үзенең программа чыгышында Р.Н.Миңнеханов конфессияләр арасында бәйләнешләрнең гармониядә яшәве мәсьәләләренә игътибар бирү кирәклеген әйтте.

Дин әһелләре форумнары үткәрү, мәгълүматнәшрият эшчәнлеген көчәйтү, радикаль һәм экстремистик агымнарга каршы тору буенча эш алып бару турында әйтелде. Традицион дини кыйммәтләрне пропагандалау юнәлешендә Президент шулай ук Болгар ислам академиясенең, яңа ачылган мөселман телеканалы «Хозур-ТВ»ның эшчәнлекләрен ассызыклап үтте. Р.Миңнеханов дини берләшмәләрнең социаль бурычларны хәл итүдә зур әһәмияткә ия булуларына басым ясады. Аерым алганда, Президент гаилә кыйммәтләрен саклауга тукталды. «Без үзгәрешләр заманында яшибез. Икътисад, социаль өлкә һәм тормыш рәвеше гел үзгәреп тора. Җәмгыять үсешендә төрле карашлы, төрле милләт һәм дин вәкилләренең гражданлык җаваплылыгы һәм социаль бердәмлеге зур роль уйный. Бу – ил һәм республика үсеше дәрәҗәсенең әһәмиятле күрсәткече. Алга таба да иҗтимагый мөнәсәбәтләрне ныгыту эшен дәвам итәргә кирәк», – дип мөрәҗәгать итте ул.

# Татарстан мөфтие – Дагъстанда: «Илебез халкын динебез берләштерә ала»



Татарстан Республикасы мөселманнары башлыгы рәсми эш сәфәре белән Дагъстанда булды. Биредә «Россия халыкларының бердәмлеген ныгытуда диннең роле» дип исемләнгән Россиякүләм дини конференция узды. Аны Дагъстан Республикасының дини оешмалар белән хезмәттәшлек, вөҗдан иреге буенча комитет һәм Дагъстан Республикасы мөфтияте оештырды.

Конференция 2018-2020 елларга «Дагъстан Республикасында террорчылык идеологиясенә каршы торуның комплексы программасы»н тормышка ашыру кысаларында үткәрелеп, экстремизм идеологиясе таралуны профилактикалау мәсьәләләренә багышланды. Әлеге чарада Россиянең һәм чит илләрнең күренекле мөселман дин эшлеклеләре һәм дин галимнәре катнашты. Алар арасында шулай ук – Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, ул «Яшьләрнең радикаль агымнарга бирелү сәбәпләре һәм факторлары» секциясендә чыгыш ясады. «Әлбәттә, аның төп сәбәбе булып халыкның дини яктан белемсез булуы тора. Әлеге чиккә барелүнең тагын бер ягы – дини фанатизм. Кызганыч ки, яшьләр һәрвакытта да белемнәрне ышанычлы һәм дөрес чыганаклардан үзләштермиләр. Шул белемнәрне сеңдереп, яшьләр аның белән гомер буе яшиләр», – дип билгеләп узды Камил хәзрәт. Тулаем алганда, җәмгыятьтә дини мәгърифәтчелек үсеше темасы конференциядә кызып җеп булып узды.

Моннан тыш, Махачкалада мөфти Дагъстан дәүләт университеты ректоры белән очрашты. Сөйләшүләр барышында Камил хәзрәт һәм Муртазали Рабаданов Дагъстан дәүләт университеты һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте арасында хезмәттәшлек мөмкинлекләре хакында фикер алыштылар. Үз эшчәнлегендә университет студентлар мохитендә экстремизм күренешләрен профилактикалауга зур игътибар бирә. Очрашу ахырында Муртазали Хулатаевич Татарстан мөфтиенә Коръәннең М.-Н. О. Османов тәрҗемәсендәге басмасын бүләк итте, үз чиратында, Камил хәзрәт Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте чыгарган «Казан басма»сын бирде.

«Россия халыкларының бердәмлеген ныгытуда диннең роле» дип исемләнгән Россиякүләм дини конференциянең пленар утырышында Камил хәзрәт Сәмигуллин мәртәбәле президиум әгъзасы буларак катнашты.




Пленар утырышта чыгыш ясап, Татарстан мөфтие Россиянең төрле төбәкләреннән килгән дин кардәшләрен сәламләде һәм үзенең фикерләрен җиткерде: «Хәзерге көндә минем белән бәрәү дә бәхәсләшә алмас: СССР таркалганнан соң илебездә милли идея калмады. Әлеге идеяне бүгенге вакытта дин генә алыштыра ала. Бары дин генә илебез халкын берләштерергә сәләтле. Моның ачык мисалы булып Дагъстан тора. Мин әле дә булса шаккатам: безнең көннәргә кадәр биредә никадәр телләр, төрле мәдәниятләр сакланып калган. Ә хәзер сорау бирик: сезне тел берләштерәме – юк, милләт – юк, ә дин берләштерә. Тикмәгә генә Дагъстанны «Россия в миниатюре» дип атамыйлар. Никадәр халыкның дин тотып яшәве сокландыра».

Сәфәр кысаларында Татарстан мөфтие Махачкалада «Ватан» радиостанциясендә кунакта булды. Камил хәзрәт Сәмигуллин «Есть разговор» тапшыруына интервью бирде. Алар танылган дин әһеле Мөхәммәдрәсүл Саадуев белән бергә бер сорауга җавап эзләде: Россия халыкларының бердәмлеген ныгыту мәсьәләсендә ислам дине нинди урын тота?

Татарстан мөфтие татар шәехе Зәйнулла Шәриф Расүлев исемендәге мәчеттә җомга намазы укытты. Үзенең вәгазендә Камил хәзрәт җыелган халыкка Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең хикмәтле киңәшен искә төшерде: «Биш нәрсә килгәнче, биш төрле әйбернең кадерен бел».

«Картлык килгәнче, яшьлегеңнең кадерен бел. Авыру килгәнче, сәламәтлегеңнең кадерен бел. Фәкыйрьлек килгәнче, байлыгыңның кадерен бел. Мәшәкатьләр килгәнче, вакытыңның кадерен бел. Үлемеңнән әүвәл яшәвеңнең кадерен бел», – дип билгеләп узды мөфти. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге киңәшләренә аңлатма биреп, Камил хәзрәт тормыштан мисаллар китерде. Моннан тыш, мөфти дин кардәшләребезне үзләрен «Коръәнчеләр» дип атаучылар идеяләреннән ерак торырга чакырды. Ул аңлатканча, «Коръәнчеләр» Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтен кире кагалар, ә бу исә бик куркыныч, чөнки Сөннәт безгә Кәлам Шәрифне аңларга ярдәм итә. Татар дин эшлеклесе хөрмәтенә төзелгән әлеге мәчет 2016 елның 1 августында ачылган иде. Аның ачылышында Татарстан мөфтиятеннән рәсми делегация катнашты.

Шулай ук Камил хәзрәт Сәмигуллин Дагъстан мөфтие шәех Әхмәд хаҗи Абдулаев белән очрашты. Очрашуда Чечен Республикасы мөфтие Сәлах хаҗи Межиев, шулай ук «Россия халыкларының бердәмлеген ныгытуда диннең роле» дип исемләнгән Бөтенроссия дини конференциясендә катнашкан башка мөхтәрәм затлар, гарәп илләреннән килгән дин галимнәре катнашты.

Камил хәзрәт Әхмәд хаҗига әлеге әһәмиятле чарага чакыру өчен рәхмәт белдерде. Шәех Әхмәд хаҗи Абдулаев, билгеләп узганча, Дагъстан Республикасына шундый мөхтәрәм кунакларның килүе – бик зур һәм мөһим вакыйга. Бу, һичшиксез, тынычлык һәм тотрыклылыкны саклау өчен, туганлык мөнәсәбәтләрен һәм хезмәттәшлекне ныгытуга этәргеч булачак, дип ассызыклап үтте ул. Моннан тыш, дин әһелләре өчен Дагъстан Республикасы мөфтияте бүлекләре буйлап экскурсия оештырылды.

■ dumrt.ru

# Шәйтанның иманны алырга теләве турында



Берәүнең җан бирү вакыты җитсә, шәйтан баш очына килеп утырыр да, ул кешегә: «Бу динне ташла, Аллаһының иптәше бар, алар икәү диген. Әгәр шулай дип әйтсәң, бу үлем катылыгыннан котылырсың», – дип котырта башлар.

Инде эш болай булса, хәлебез бик тә куркыныч булачак. Шуның өчен син, мөэмин-мөселман, шәйтан коткысына бирелеп, бу дөньядан имансыз китмәс өчен, һәрдаим елый-елый Аллаһы Тәгаләгә ялвара торган бул! Төннәрен йокыңны ташлап, рөкугъ һәм сәҗдәләр кыл. Шулай эшләсәң генә, Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең газабыннан котылырсың.

Имам Әгъзам Әбү Хәнифәдән: «Гөнаһларның кайсылары кешене имансызлыкка төшерә?» – дип сорагач: «Иманлы булуыңа шөкер кылудан туктау, үлгән вакытында бу дөньядан имансыз китүдән курыкмау һәм кешеләргә җәбер-золым итү. Берәүнең күңелендә бу өч төрле сыйфат пәйда булса, ул кешенең бу дөньядан имансыз китү куркынычы бар», – дип җавап биргән. Бу сыйфатлары булган кешеләрдән Аллаһының фазыл-рәхмәтенә ирешә алганнары гына иман белән китәргә мөмкин.

Үлеп барган кешенең иң авыр вакыты – сусаудан йөрәге көйгән вакыты. Шул вакытта шәйтан, кешенең иманын юкка чыгарыр өчен, юл эзләп таба. Сусаган кеше янына килеп, шәйтан бер савыт сап-салкын, бозлы су күрсәтер. Бу сусаган мөэмин моны күргәч, шәйтаннан шул суны бирүен үтенер. Шәйтан: «Дөньяны яратучы Аллаһы юк дисәң, бирермен», – дип әйтер. Әгәр дә бу кеше изгеләрдән булып, шәйтан сүзенә җавап бирмәсә, шәйтан бу кешенең баш очыннан аяк очына барыр да янә шул савыттагы суны күрсәтер. Тегe кеше тагын су бирүне үтенер. Шәйтан: «Мөхәммәд галәйһиссаләтү вәссәлам ялганчы дип әйтсәң, бирермен, юкса, бирмим», – дип кабатлар. Инде берәү, яманнардан булса, шәйтанның сүзен кабул итеп, җавап бирер дә, дөньядан имансыз китәр. Әгәр дә изгеләрдән булса, шәйтанның сүзен кабул итмәс, аны инкарь итәр. Үзенең кайда барачагын, үзенә ниләр кирәген исеннән чыгармас һәм сәламәт калыр.

Хәбәрләрдә риваять ителә: Әбү Зәкәрия атлы заһид, галим, үлем исереклегендә ята икән. Якыннары, туганнары килеп, аңа «Ләә иләәһә илләллаһ, Мөхәммәдәр Расүлуллаһ» сүзләрен әйттерергә тели. Әбү Зәкәрия йөзен читкә бора, бу сүзләрне нигәдер кабатламый. Якыннарыннан булган бер иптәше, йөзен борган якка чыгып, тагын «Ләә иләәһә илләллаһ, Мөхәммәдәр Расүлуллаһ»ны, кәлимәи таййибәне әйттермәкче була. Әбү Зәкәрия янә йөзен икенче тарафка бора. Шуннан соң дусты өченче тапкыр тәлкыйн кылып карый, ягъни «Ләә иләәһә илләллаһ, Мөхәммәдәр Расүлуллаһ» сүзен кабатлаттырмакчы була. Әбү Зәкәрия бу юлы да: «Әйтмим!» – ди. Иптәше моның өчен кайгыруыннан аңын җуеп, хушыннан яза. Соңрак Әбү Зәкәрия бераз вакыттан соң аңына килеп: «Сез миңа берәр сүз әйттегезме әллә?» – дип сорый. Иптәше: «Без сиңа өч тапкыр кәлимәи таййибәне әйтеп карадык. Син ике мәртәбәсендә йөзеңне бордың, өченче мәртәбәсендә «әйтмим» дидең», – дип сөйләп бирә. Әбү Зәкәрия: «Минем яныма кулына бер савыт су тотып, Иблис ләгънәтуллаһи галәйһи килгән иде. Син суга мохтаҗ, әгәр дә Гайсә Аллаһның углы дисәң, бирәм, ди. Мин йөземне аңардан икенче якка бордым. Янә сул ягыма килеп, тагын шул сүзне кабатлады. Мин тагын йөземне бордым. Өченче мәртәбәсендә «Аллаһ юк» дисәң, суны бирермен, диде. Мин шунда аңа җавап итеп: «Әйтмим!» – дип кычкырдым. Минем Иблис белән сөйләшүем сезнең сүзләрегезгә туры килгәндер. Мин сезнең сүзегезне ишетмәдем. Шуннан соң Иблис савытны җиргә ташлап, янымнан качып китте. Инде мин Аллаһы Тәгалә бердәнбер, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аның пәйгамбәре һәм хак Илчесе дип гуаһлык бирәмен, ант итәм! Ләә иләәһә илләллаһ, Мөхәммәд Расүлуллаһ», – дип җан бирә.

Шул ук хәбәрдә Мансур бине Гомәрдән китерелә: «Берәүнең үлем вакыты килсә, аның хәле биш бүлеккә бүленер. Малы – варисларга, җаны – үлем фәрештәсенә, ите – кортларга, сөякләре – туфракка, изгелекләре – җәбер иткән кешеләргә. Шул вакыт шәйтан иманны сорар өчен хәзерләнеп торыр. Әгәр варислар малны алып китсә, куркыныч түгел. Әгәр дә үлем фәрештәсе җанны алып китсә, бу да артык яман түгел. Кортлар тәндәге итләрне ашап бетерсәләр, монда да бик артык хәсрәт юк. Һәм дә үзеннән җәберзолым күрүчеләре изгелекләрен алып китсәләр, бу да ярый әле. Әмма шәйтан иманны алып китсә, эш бөтенләй харап булыр. Чөнки бу гомер буе тоткан диннән аерылу буладыр. Җанның тәннән аерылуы бик үк куркыныч түгел әле ул. Иң куркынычы – Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләдән, Раббыбызның рәхмәтеннән аерылу. Чөнки бу Аллаһы Тәгалә кушмый, сөйми торган аерылу була».

# Кыямәтнең куркынычлыгы турында

Дөньяда булган сәгатьләрнең иң авыры – үлгән вакытта тел тотылгач, җанның чыгарчыкмас вакытыдыр. Кеше җаны чыкканда, ни хәлдә булуы турында үткән бүлекләрдә сөйләнелде. Әмма Ахирәттәге иң куркыныч һәм дә адәм баласы өчен иң авыр булган вакыт – сур өрелеп, кабердәге затлар кубарылып, мәзлүмнәр (рәнҗетелгән кешеләр) золым итүчеләргә (үзләрен дөньяда вакытта рәнҗетүчеләргә) хакларын сорап, якаларына ябышкан чаклары. Чөнки бу вакытта, залимнарның кылган эшләренең шаһитлары фәрештәләр булып, сорау алучы Аллаһы Тәгалә Үзе булачак, җәһәннәмнең газабы, җәннәтнең нигъмәте күренеп торачак. Шул кадәр куркыныч булачак ки, хәтта яшь сабыйлар куркуларыннан картаеп чыгачаклар.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә: «Ул көнне җир барысы турында сөйләп бирер», – дип әйтә.

«Зүлләзиләт / Җир Селкенмәк», 99:4

Хәбәрдә болай дип китерелә: «Адәм баласының дөньяда кылган эшенә җиде төрле шаһит булыр:

1) җир;
2) вакыт (ягъни көн, төн). Вакыт һәркөнне: «Әй, адәм баласы, мин яңа көн! Сиңа, кылган эшләреңә таныклык кылам, ягъни шаһит булып торам», – дип кычкыра икән;
3) тел;
4) тән әгъзалары (куллар, аяклар). Боларның шаһит булулары Коръәндә бәян ителә;
5) ике фәрештә;
6) гамәл дәфтәре;
7) Аллаһы Тәгалә Үзе.

Әй, гөнаһка чумучы! Ошбу үзеңнең зарарыңа җиде шаһит гуаһлык, шаһитлык биргән вакытта синең хәлең ничек булыр? Шуның турында уйлан».

■ **«Дакаикуль-әхбәр. Үлем һәм ахирәт хәбәрләре» китабынна, «Хозур» нәшрияты, 2018**

# Бала, анын беренче адымнары

Менә кычкырып елап дөньяга бала килә. Бала үзенең нинди катлаулы, мәшәкатьле дөньяга килүен, Аллаһ хозурыннан аерылуын аңлый, шуңа күрә елый. Әгәр еламаса, аңы нормаль түгел икәнен күрсәтә. Аның елавы: «Әти-әни, сез минем дөньяга килүемә сәбәпче булдыгыз, хәзер инде нинди тәрбия биреп, нинди юлларга керергә мәҗбүр итәрсез», – дип әти-әнисенә мөрәҗәгате.

Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам: «Бала дөньяга фитри иман белән килә. Аны әти-әнисе йә насари, йә яһүди, йә мөселман яки бөтенләй динсез итә», – диде. Бала сөйләшә белмәсә дә, аңлый, аның янына теләсә кемне кертергә ярамый, үзенә дә ачулы чагында читтәрәк булу кирәк. Тупас холыклы, явыз, ачулы кешеләр янына килү баланың аңына начар тәэсир итә һәм ул борчыла. Балага караган кеше яратып, сөеп: «Сүбехәнәллааһ», дип әйтергә тиеш. Артык сокланып карау, өстенә кисәк нидер әйтү баланың берничә көн борчылуына китерүе мөмкин, халыкта аны «күз тию» дип атыйлар.

Азан әйтеп, күркәм исем кушу бик мөһим. Азан тавышы балага аның бу дөньяда ялгыз түгеллеген, бу дөньяда да аңа ярдәмгә пәйгамбәрләр аркылы бирелгән дини юл барын белдерә һәм тынычландыра. Ир бала тугач – ике сарык, кыз бала тугач – бер сарык корбанга чалып, дусларны, туганнарны җыеп, Коръән укытып кунак итү – сөннәт, саваплы эш. Бу «гакыйка корбаны» дип атала.

Гаиләдә ир кеше баш булып, аны матди яктан тәэмин итәргә, куркынычлардан сакларга тиеш. Әни кеше бала тәрбияләүдә баш була, әти кеше аның ярдәмчесе генә.

Бала тугач та аңарда фәрештә сыйфатлары өстенлек итә. Тирә-юньдәге кешеләр, ашаган ризыгы йогынтысында шайтани һәм хайвани сыйфатлары да үсә башлый. Баланы кулга алганда әни кешенең тиешле киемдә, тәһарәтле, госелле булуы, «бисмиллаһ» әйтеп ашатуы зарур. Теләсә нинди хатын-кыз яланбаш килеш өйгә керсә, госелсез кешеләр баланы уйнарга, сөяргә дип кулларына алса, авызына теләсә нинди ризык каптырса, өйдә зәвыксыз музыка уйнап торса, әдәпсез фильмнар каралса, тавыш-гауга булса, өлкәннәргә хөрмәт булмаса, өйдән фәрештәләр кача һәм бала шайтан йогынтысында кала. Киресенчә, өйдә азан әйтелсә, намаз укылса, Коръән аятьләре укылса, дустанә мөнәсәбәт булса, бала фәрештәләр йогынтысында була.

Аллаһ Раббыбыз Коръәндә: «Һәрнәрсәнең үз вакыты бар», – диде. Шуңа күрә дә тизрәк утырып торсын, тизрәк аякка бассын, йөреп китсен, дип чамадан тыш ашыктырып, баланы азаплау зарарлы. Баланың теле «әти-әни» дип ачылуга караганда, «Аллаһ» дип ачылуы хәерлерәк. Бала ишетә башлау белән, аның янына килгән һәр кешенең әкрен генә: «Аллаһ, Аллаһ», дип әйтүе хәерле. «Аллаһ» дип теле ачылган бала дөньядан имансыз китмәс», – дигән хәдис бар. Сөйләшә башлагач, баланың: «Мин кайдан килдем», – дигән соравына җавап: «Аллаһ бирде», – булырга тиеш.

7 яшькә кадәр балага намаз өйрәтелмәсә дә, аңа: «Аллаһ бар, Ул – мәрхәмәтле, яхшы, гүзәл, бар нәрсәне күреп, белеп тора, кешеләрне беркайчан да Үз рәхмәтеннән ташламый», – дигән төшенчәләрне аңлату зарур.

Бүген бик күпләрнең тормышта югалып калулары, аның сынауларын үтә алмаулары, эчкечелеккә, наркоманиягә бирелүләре ышанычлары булмаудан килә. Кеше тормыштан туймасын, кыенлыклар алдында югалып калмасын, дисәк, Аллаһка ышануны бала вакытта ук тәрбияләргә һәм бу ышаныч гомер буе югалмасын өчен бөтен көчне куярга кирәк.

Баланы без әкренләп табигатьне танырга, яратырга өйрәтергә тиеш. Баланың фикерләү сәләтен үстерүдә табигать белән таныштыру бик мөһим. Аны дәрес итеп түгел, ә табигать кочагында үзара әңгәмә рәвешендә алып бару кирәк. Балаларга үсемлекләр, җәнлекләр, бөҗәкләр, кошлар турында мавыктыргыч хикәяләр сөйләү, алар белән җиләккә, гөмбәгә йөрү дә бик файдалы. Бала табигатьне күзәтергә, аңа сокланырга һәм аны яратырга, хөрмәт итәргә өйрәнә. Әлбәттә инде, ул шушы самими гүзәллекнең иҗат итүчесе барын һәм аның Аллаһ булуын, һәрнәрсәнең урынлы һәм әһәмиятле булуын төшенергә тиеш. Әгәр балада табигатьне танып белү теләге уята алсак, белемгә һәм Аллаһны танырга омтылыш тудырдык, дигән сүз.

■ **Җәлил хәзрәт Фазлые,**
**ТҖ баш казые**

# XX гасыр татар мәдрәсәсе тәҗрибәсеннән

**Мөгаллим** – Углым! Ошбу алдыңдагы өстәлне күрәсеңме? Моны кем ясады икән?

**Шәкерт** – Балта остасы ясаган, әфәндем.

М. – Ярый, углым. Берсе сезгә килеп: «Бу өстәл үз-үзеннән ясалды: соңра үзе бу сыйныфка килде», – дип әйтсә, ышанырсызмы?

Ш. – Юк, ышанмам.

М. – Ни өчен ышанмыйсыз?

Ш. – Ничек ышаныйм, өстәл үзеннән-үзе ясалырмы?

М. – Алай булгач ничек ясалыр?

Ш. – Балта остасы ясар, әфәндем.

М. – Ярый, углым, бу өстәлне бер ясаучы булган кебек, бу ишекне дә бер ясаучы бармы ,юкмы?

Ш. – Бар, әфәндем.

М. – Кем соң?

Ш. – Янә балта остасы.

М. – Ошбу күргән рәсемләрегез үз-үзләреннән генә бар булганнармы?

Ш. – Юк, боларны бер ясаучы бар.

М. – Алай булгач, тирә-ягыбыздагы нәрсәләрнең һич берсе үз-үзеннән булмаганнар, барысын да бер ясаучы бар түгелме, углым? Безне, башка адәмнәрне дә бер ясаучы вә бер ярату-чы юкмы соң?

Ш. – Бар ,әфәндем.

М. – Ярый, кем ул?

Ш. – Аллаһы Тәгалә.

М. – Афәрин, углым! Аллаһы Тәгалә ялгыз безне генә яратканмы? Хайваннарны кем яраткан?

Ш. – Аллаһ...

М. – Йә, бу без өстендә яшәгән җирне, ташларны, агачларны, диңгезләрне, елгаларны, күкләрне ... вә башка бөтен нәрсәләрне яратучы кем?

Ш. – Янә Аллаһы Тәгалә.

М. – Ярый, «яратмак» ни дигән сүз?

Ш. – Ясамак дигән сүз.

М. – Әйе ,углым. Ләкин нинди ясау икәнен беләмсезме? Һич юктан ясау. Бу санаган нәрсәләремезнең һич берсе электән юк иде. Җәнабе Аллаһ боларны һич юктан ясады, яратты... Берсе сезгә мәсәлән: «Адәмнәр бу дөньяга үз – үзләреннән чыктылар», – дисә, ышанырсызмы?

Ш. – Юк, әфәндем!

М. – Йә, ни дип әйтерсез?

Ш. – Аллаһ яратты, дип әйтербез.

М. – Аллаһы Тәгаләнең безгә зур-зур яхшылыклары бармы?

Ш. – Әлбәттә бар.

М. – Әгәр яңгырлар яумаса, игеннәр үсәр идеме?

Ш. – Юк, үсмәс иде.

М. – Ярый, алай булгач яңгырларны яудыручы, игеннәрне үстерүче безгә икмәк яратучы кем, углым?

Ш. – Аллаһы Тәгалә, әфәндем.

М. – Йә, сез сөйләгез без ашта ни ите ашыйбыз?

Ш. – Куй ите, сыер ите.

М. – Тагын?

Ш. – Тавык ите.

М. – Ярый, углым, боларның барысын да яратучы кем?

Ш. – Янә Аллаһы Тәгалә.

М. – (Мөгаллим бу мәудугны бераз тагын кичектергәч) Алай булгач, ашаганыбызны, эчкәнебезне, кигәнебезне вә бөтен нәрсәләрне кем яратты?

Ш. – Аллаһы Тәгалә яратты.

М. – Без ни аркасында яшибез?

Ш. – Бу нәрсәләр аркасында яшибез?

М. – Ул хәлдә Аллаһы Тәгалә безгә иткән бу кадәр яхшылыкларына каршы шөкерана кылыра бурычлыбызмы?

Ш. – Әйе, әфәндем.

М. – Ялгыз шөкерана кылу гына җитәме? Аллаһ ни кушса, аны эшләмикме?

Ш. – Эшлик, эшләргә бурычлыбыз.

М. – Әгәр дә «шул эшне эшләмәгез» дисә..?

Ш. – Аны эшләмәскә кирәк.

М. – Ярый, углым. Аллаһы Тәга-ләнең ни эшләгәнебезне теләгәнен вә ни эшләгәнебезне яратмаганлыгын кайдан белик? Аллаһы Тәгалә тарафыннан берсе килеп безгә: «Аллаһы Тәгалә ошбу эшләрне ярата, аларны эшләгез; менә бу эшләрне бер дә яратмый, алардан сакланыгыз вә аларны эшләмәгез», – дип әйтергә тиеш түгелме?

Ш. – Әйе, әфәндем, әйтергә тиеш.

М. – Әгәр дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан берсе килеп, безгә сөйләмәсә, хәбәр бирмәсә, без Аллаһ ни теләгәнне белә алырбызмы?

Ш. – Юк, белә алмабыз.

М. – Аллаһы тарафыннан килеп тә, безгә Аның теләгән вә теләмәгән нәрсәләрен белдергән кемсәгә ни диләр, беләсезме?

Ш. (тик торыр)

М. – Аңа «пәйгамбәр» дип әйтәләр.

Ш. – Хәлфә әфәнде, пәйгамбәр ничек була ул?

М. – Углым, пәйгамбәр дә безнең кебек бер кешедер. Ул да ашый, эчә, утыра, йөри, аның да авызы, борыны, күзе, колагы бар. Ялгыз Аллаһның бик сөекле бер колы булганлыгы өчен Җәнабе Аллаһ аңа: «Әйдә бар да, яраткан адәмләргә, колларыма Минем сөеп вә сөймәгән нәрсәләремне өйрәт», – дип боерган. Пәйгамбәр дә килеп безгә: «Менә сезне юктан бар иткән, сезнең өчен бу кадәр яхшы вә матур нәрсәләр яраткан Аллаһы Тәгалә ошбу нәрсәләрне куша, боларны эшләгез; бу нәрсәләрне теләми вә сөйми, аларны эшләмәгез», – дигән. Аңладыгызмы?

М. – Углым, безнең пәйгамбәребез кем, беләсеңме?

Ш. – Хәзрәти Мөхәммәд.

М. – Афәрин, углым!

Ошбу рәвешчә дәвам итеп, Пәйгамбәребез хакында мәгълүмат биргәч, Коръән Кәрим вә дин Ислам хакында мәгълүмат биреп, дәресне тәмам итәдер.

■ **«Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллиме Габдулла Шәнаси, 1912 ел**

# Алдау юлы белән табыш

Кешеләрне алдалап табыш җыю – Ислам динендә генә түгел, гомумән, бик түбән һәм җирәнгеч сыйфатлар булып санала. Хаклыкны бозып күрсәтү, кешеләрне ялгыш фикерләргә кертү – тугры кешеләргә хас булмаган гамәлләр. Тугры кеше ихлас, гадел, хәйләсез, беркайчан да алдаламас, беркайчан да кешенең хакына кермәс зат була.

Коръәндә дә, сөннәттә дә мондый төр гамәлләр, ягъни золымлыклар мөселманнарга карата да, мөселман булмаган кешегә карата да тыелган. Мөселман булмаган кеше дә Кыямәттә үзенең хакын алачак, шуңа күрә Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам кеше хакына керүне һәрвакыт тыеп килде.



## Мөселман алдакчы була аламы?

Ислам дине туры юлны гына кабул итә. Бу юлга кергән кеше ялганның барлык төрләреннән дә баш тартырга тиеш. Имам Бәйһакый җыентыгында түбәндәге хәдисне табарга мөмкин: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламнән: «Мөселман кеше куркак була аламы?» – дип сорадылар. Ул галәйһис-сәлам: «Әйе, була ала», – дип җавап кайтарды. Шуннан соң: «Мөселман кеше саран була аламы?» – дип сорадылар. Ул шулай ук уңай җавап кайтарды. Соңыннан: «Мөселман кеше алдакчы була аламы?» – дип сорадылар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам: «Юк, беркайчан да», – дип җавап кайтара». Күз алдыгызга китерегез, мөселман кешесе беркайчан да алдаламас, дип әйтелә. Ә кеше шушы алдау нәтиҗәсендә табыш та алса, бу бит икеләтә авыр гөнаһ дигәнне аңлата түгелме соң? Беренчедән, ул кешеләргә дөрес булмаган мәгълүмат бирә, икенчедән, үзенә тыелган табыш ала. Бохари хәдисләр җыентыгында шулай ук алдалау, ялган турында бик күп хәдисләр табып була. Мәсәлән, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам: «Кем безгә каршы корал күтәреп чыкса, ул бездән (мөселманнардан) түгел. Кем безне алдалый, ул да бездән (мөселманнардан) түгел», – дип әйткән.

Көннәрдән бер көнне сөекле Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам базарга бара. Бодай сатучы яныннан узып барганда, ул туктап, кулын бодай өеменә тыгып карый һәм бодайның аста бераз юеш булуын белеп ала. Кулын чыгарып ул сатучыдан: «Нәрсә бу?» – дип сорый. Бодай сатучы: «Йә Расүлуллаһ! Күптән түгел генә яңгыр явып китте, шуңа күрә бодай бераз юешләнде», – дип җавап бирә. Аллаһның илчесе: «Алай булгач, кешеләр күрсен өчен, юешләнгән өлешен өстә калдырырга иде», – дип таләп итә. Алга таба: «Безне алдаучы кеше бездән түгел», – дип өстәп куя.

Ислам дине кеше яшәешенең һәр тармагын колачлый. Әлеге хәдис безгә нәрсә хакында сөйли? Мөселманнар бервакытта да кешеләрне алдаган, үзләренең бер мизгеллек дөньяви файдалары өчен башкаларны ялгыш юлга этәргән кешеләр белән бергә булмаслар. Һичшиксез, Ислам дине сәүдә белән шөгыльләнүне хуплый. Расүлуллаһның әйтүе буенча, тугры сүзле, ышанычлы һәм гадел сәүдәгәрләр пәйгамбәрләр, әүлияләр һәм изге гамәлле кешеләр белән бергә кубарылачаклар. Шуңа күрә сату-алу яисә башка табыш китерә торган эшчәнлек белән шөгыльләнгән кешеләр бик гадел һәм намуслы эш итәргә тиешләр. Әгәр дә сатыла торган әйбернең берәр кимчелеге булса, сатучы ул хакта сатып алучыны кисәтергә бурычлы. Гыйбадәт кылганда үзеңне Аллаһы Тәгалә каршында басып торгандай хис итеп, ихсан белән кылырга кирәк булган кебек, сәүдә, бизнес һәм башка эш белән бәйле мөнәсәбәтләрдә дә Аллаһы Тәгалә безне һәрдаим күреп торуын истә тотарга кирәк.

## Пәйгамбәребез кемнәрне кире кагар?

Мөселман җәмгыятьчелеге һәрбер мөселманга карата саф һәм чиста хисләр, ихласлык белән, берберең̧ә биргән вәгъдәләрнең үтәлүе белән корыла. Мөселман җәмгыятендә диндар, тәкъва, тугры кешеләр генә булырга тиеш. Ә алдалау, шул юл белән табыш алу – болар барысы да мөселман җәмгыятенә туры килми торган, мөселман кешесенә чит-ят әйберләр. Шуңа да мөселманнар арасында алдакчылар да, алдалап кәсеп кылучылар да булырга тиеш түгел. Алдалау һәм алдалап табыш алу ислам динендә кабахәт эш булып санала. Югарыдагы хәдисне искә алганда, Пәйгамбәребез алдакчыларны гомумән мөселманнар рәтеннән читкә чыгара. Шулай ук Кыямәт көнендә хыянәтчеләрне үзләренең хыянәтләре белән кубарылачагын да әйтте. Хыянәтчене барлык кешеләр арасыннан исеме белән чакырып алырлар. Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә болай дип әйтелә: «Кыямәт көнендә һәрбер хыянәтчедә аның хыянәт билгесе булачак. Аны: «Бу фәлән һәм фәлән кешегә хыянәт иткән кеше», – дип атый башлаячаклар (Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан). Чыннан да, Кыямәт көнендә хыянәтче ир-ат һәм хатын кызларның хурлыклары бик зур булачак. Бу дөньяда үзләренең гаепләрен оныткан һәм Кыямәттә берни дә булмаячак, дип уйлаган кешеләр Ахирәттә бик каты үкенәчәкләр. Беренчедән, аларның гаепләрен бар халыкка күрсәтәчәкләр, икенчедән, хыянәт билгеләрен үзләренең куллары белән кешеләр алдында күтәреп йөриячәкләр. Андый кешеләрнең хәлләре Кыямәттә Пәйгамбәребез Мөхәммәд белән очрашкач, тагын да начарланачак. Аларның бу кабахәт гамәлләре Пәйгамбәребезнең шәфәгатеннән, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән мәхрүм итә ала. Андый кешеләр Кыямәттә мөфлис, ягъни банкротка чыга ала. Мөхәммәд галәйһис-сәлам болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә: «Мин өч төрле кешене: вәгъдә биреп тә, аны үтәмәгән; ирекле кешене коллыкка сатып баеган; берәр хезмәт өчен кеше яллап, аңа хезмәт хакын аз түләгән кешене (лаеклы хезмәт хакы түләмәгән кешене) Кыямәт көнендә кире кагачакмын», – дип әйтте».

## Мөнафикъларның 4 билгесе

Ялганның һәр төреннән дә ерак торырга кирәклеге турында әйттек. Бу җәмгыятьтәге барлык төр мөгамәләгә дә кагыла. Без имтиханнарда, бизнес эшләрендә, хәтта гаилә мөнәсәбәтләрендә дә ялган кулланабыз. Кемдер ялган продукциягә чит ил маркалары ябыштырып, аларны импорт дип сата; кемдер киңәш сорап килгән кешегә дөрес булмаган киңәш бирә. Хатыннар ирләренә, ирләр хатыннарына хыянәтне гөнаһ дип тә белмиләр. Әмма бу гамәлләрдән мөселман кешесе генә түгел, әһәрберебез качарга тиешбез. Мөхәммәд галәйһис-сәлам болай дип әйткән: «Мөнафикъның 4 төрле билгесе бар. Кемдә бу галәмәтләрнең барысы да булса, ул кеше чын мәгънәсендә икейөзле кеше булып санала, ә кемдә бу галәмәтләрнең берсе булса, ул кешедә монафикълык билгеләре бар дигәнне аңлата. Бу сыйфатлар: әманәтенә хыянәт итү; сөйләгәндә ялганлау; вәгъдәдә тормау; берәр кеше белән бәхәсләшкәндә, бохтан сөйләү» (Имамнар Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыкларыннан). Ихлас һәм тәкъва мөселманнар бу төр гамәлләрдән: ялган, хәйлә, хыянәт итүдән ерак торалар. Алар нинди генә зур табыш алып килергә ярдәм итмәсен, барыбер алардан ерак торырга кирәк, чөнки икейөзлелек тә Ислам диненә кагылышы булмаган кабахәт гамәлләрдән саналалар.

Аллаһы Тәгалә базарда, кибеттә киметеп үлчәүчеләр турында болай дип әйтә:

**«Киметеп үлчәүчеләргә үкенече каты газапдыр. Алар башка кешеләрдән берәр нәрсә үлчәп алсалар, үлчәүне тутырып, мул үлчәп алалар. Әгәр башка кешеләргә савыт яки бизмән белән үлчәп биргәндә, киметеп үлчиләр. Әллә ул кешеләр терелеп кубарылачакларын уйламыйлармы».**

«Мутаффифин / Киметүчеләр», 83:1-4

Бу гамәлләрнең газабы зур булганга күрә, алар турында Коръәндә дә, Сөннәттә дә бик күп кисәтелә. Кибет тоту кебек эшләр матди яктан керемле эш булып тоелса да, аларның шулай ук бик җитди һәм җаваплы хезмәт икәнен дә истән чыгарырга ярамый.

**■ Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев, Хәсәншәех авылы**

# ИКЕ НУР ИЯСЕ – ГОСМАН
## разыйаллаһу ганһе



### Госманның Ислам динен кабул итүе

Госман разыйаллаһу ганһе Пәйгамбәребез Мөхәммәдтән (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) 6 яшькә кечерәк булып, якынча 577 елда Мәккәдә туган. Ул ислам динен 30 (кайбер чыганакларда 34 дип килә) яшендә, Әбү Бәкернең дәгъвәты белән кабул итә. Якыннары аның бу гамәлен хупламаган. Ул абыйлары тарафыннан төрлечә эзәрлекләүләргә дучар була, төрле газап-җәфалар күрә. Башта аяк-кулларын бәйләп, базга ташлыйлар, соңыннан төтен белән буалар. Ләкин нинди генә авырлыклар күрсә дә, ул диненә тугры кала.

### Госман разыйаллаһу ганһенең һиҗрәте

Мәккә мөшрикләре тарафыннан мөселманнарны кысрыклау, газаплаулар арткач, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарга Мәккәдән Һәбәшкә һиҗрәт кылырга рөхсәт итә.

Госман разыйаллаһу ганһе хатыны Рокыя белән 12 ир-ат һәм 4 хатын-кызны ияртеп, Һәбәшкә (Эфиопия) һиҗрәт кыла. Бу вакыйга 5 нче пәйгамбәрлек елының раҗәб аенда була. Коръәндә дә Аллаһы Тәгалә алар турында искә ала:

**«Залимнәрдән золым күргәннән соң, хак мөэминнәр иркен урынга күчеп киттеләр. Без аларга дөньяда ук яхшы тормыш бирербез. Дөреслектә, аларга ахирәттә биреләчәк нигъмәт олырак, әгәр шуны кешеләр белсәләр».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:41

### Госманның Аллаһы Тәгаләдән куркуы

Хәзрәти Госман разыйаллаһу ганһе ихлас, тәкъва мөселманнардан була. Җаһилият заманында да ул беркайчан да потларга табынмаган, әдәпсезлек күрсәтмәгән, җирәнгеч гамәлләр (зина) кылмаган, шәраб кулланмаган. Гаять дәрәҗәдә инсафлы, юаш, миһербанлы, олы йөрәкле, киң күңелле, гүзәл холыклы булган; янына килгән кешеләрне үзеннән разый итеп җибәрергә тырышкан.

Һәркемгә игътибарлы, гадел мөгамәләле, башкаларга золым, хыянәт итүдән, өстендә кеше хакы калудан бик курыккан, хәтта, үзенең гаиләсе һәм хезмәтчеләренең дә хәтерләрен калдыруны сөймәгән. Якын һәм ерак кардәшләренең һәммәсен үзеннән разый итәргә тырышкан. Аллаһ исеме белән ант итүдән бик нык сакланган. Беркайчан да сүзен уйламыйча әйтмәгән. Тел афәтеннән саклану өчен авызына таш кабып йөргән.

### Холкына хас сыйфатлар

Госман разыйаллаһу ганһе бер яктан тугры булса, икенче яктан бик тә тыйнак була. Үз дәрәҗәсенә карамастан, барлык кешеләр белән дә бер дәрәҗәдә сөйләшә. Ул бик оялчан кешеләрдән санала. Шул сәбәпле, сәхабәләр дә аның янында кыек эш эшләргә батырчылык итмиләр.

Аңа йомшаклык кебек күркәм сыйфат та хас була. Ул үз мәхәллә халкына йомшак мөнәсәбәттә булган һәм өммәте өчен бик нык борчылган.

Шулай ук ул үзенең юмартлыгы белән дә танылган:

1) һәр җомга саен бер кол азат иткән (сатып ала торган булган), барлыгы 2400 кол азат иткәнлеге билгеле;

2) күп сәхабәләрнең бурычларын кичерә (Талхә разыйаллаһу ганһенең генә дә 50 мең дирһәм бурычын кичергән);

3) үзенә кадәр булган хәлифәләрнең барысына да тугры булырга ант иткән. Әбү Бәкергә, Гомәргә дәүләт белән идарә итәргә ярдәм итә.

5) ул беркайчан да биргән сәдакалары белән мактанмаган, киресенчә, уң кулы биргәнне сул кулы күрмәсен дип тырышкан.

### Госман разыйаллаһу ганһенең дәрәҗәсе

Госман разыйаллаһу ганһе сәхабәләр арасында иң югары дәрәҗәдә була:

1) Өченче тугры хәлифә.

2) Исән чагында ук җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе.

3) Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Әбү Бәкер, Гомәр разыйаллаһу ганһүмнәрдән соң иң яраткан кешесе.

4) Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ике кызына никахланып, «Зин-Нурәйн» («ике нур иясе») исеменә лаек булучы.

5) Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм урынына вәкил (Хөдәйбия солыхы төзелгән вакытта) булып калучы.

### Госман разыйаллаһу ганһенең хәлифәлеге

Хәзрәти Госман разыйаллаһу ганһе хәлифә булганнан соң, тирә-яктагы әмирләргә халыкка карата гадел һәм тугры булырга боерыклар җибәреп, аларга яхшы мөгамәлә күрсәтергә, һәртөрле халык арасында тигезлекне сакларга, ятимнәрне һәм башка диндә булган кешеләрне яклау астына алырга боера.

Госман үзе дә зур байлардан, оста сәүдәгәрләрдән булганлыгы өчен, аның заманында сәүдә, байлык, тормыш дәрәҗәсе бик нык үсә. Халык арасында төрле кәсеп һәм һөнәр ияләре, сәнгать һәм игенчелеккә әһәмият бирүчеләр арта. Фарсы Һәм Рум илләрендә булган бик күп файдалы сәнгать һәм һөнәрләр тарала. Мөселманнар арасында зур байлар, яхшы тормышка әһәмият бирүчеләр, гомумән, ислам дине әһелләре һәм фәкыйрьләр файдасына зур ярдәм күрсәтүчеләр күбәя.

### Госман разыйаллаһу ганһенең мәшһүр эшләре

1) Госман разыйаллаһу ганһе идарә иткән чорда ислам зарарына тырышучы дошманнар белән төрле җирләрдә сугышлар алып барыла һәм ислам мәмләкәтенә кертелә. 28 нче һиҗри елда Төньяк Африка илләре, 30 нчы һиҗри елда Кипр утравы, 31 нче һиҗри елда Византия җирләре, 32 нче һиҗри елда Кавказ илләре.

2) Шулай ук ул идарә иткән чорда Әрмәнстан, Әзербайҗан, Тунис һ.б. дәүләтләр яулап алына.

3) Мөселманнарның беренче тапкыр флотилиясе төзелә (600 көймәлек флот).

4) Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһе хәлифәлек иткән дәвердә Изге Коръән бер китап булып җыела һәм бу бердәнбер нөсхә була. Бераз соңрак мөселманнар арасында Коръән уку буенча төрле сораулар туа. Шуннан соң Госман разыйаллаһу ганһе мөселманнар арасында төрле фикер каршылыклары, бидгать гамәлләр килеп чыкмасын өчен Коръән укуның бердәм формасын расларга карар кыла. Ул әзер мосхафның җиде күчермәсен ясап, җиде төбәккә тарата (Мәккә, Мәдинә, Куфа, Басра, Йәмән, Мисыр, Шам).

5) Җомга намазына икенче азан әйтүне кертә. Беренче азан халыкны җыю өчен әйтелгән булса, икенче азан хәрам вакыт кергәнне хәбәр итү өчен әйтелә.

6) Сәхабәләр арасында малы белән иң күп ярдәм итүче, иганәләре белән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне һәм бөтен сәхабәләрне шатландыручы зат та Госман разыйаллаһу ганһе була. Ул үз акчасына Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәчете янындагы җирләрне сатып алып, Расүлуллаһның мәчетен зур итеп, бизәкләп төзетә. Мәчетне беренче мәртәбә зиннәтләп төзүче дә ул була.

7) Мәккә шәһәрендәге Хәрам мәчетен киңәйтә.

8) Мәдинәдә хөкем йорты (дом правосудия) төзетә. Шулай ук ул ислам дәүләтендә беренчеләрдән булып полиция (тәртип саклау) бүлегенә нигез сала.

9) Мөэзиннәргә махсус эш хакын билгели.

### Госман разыйаллаһу ганһенең шәһид булып китүе

Госман разыйаллаһу ганһе хәлифәлеге вакытында Ислам дәүләте чәчәк ату чорын кичерә. Халык арасында гыйлем, мәгърифәт, байлык арта. Хәлифә миһербанлы, мөлаем булганга халык та аны ярата. Ислам дәүләте зурая. Шуңа да 80 яшенә җиткән Госман разыйаллаһу ганһенең игътибары җитми башлый. Шул сәбәпле, ул идарәгә үзенең якын кардәшләрен кертә, ләкин алар аның ышанычын акламыйлар. Үзләре теләгәнчә, хәлифә рөхсәтеннән башка кайбер гамәлләр кылалар, фетнәләр чыгаралар. Фетнәчеләр Госман бине Гаффән яшәгән йортны камауга алалар. Аннан хәлифәлекне азат итүен таләп итәләр. Әл-Мәүт Әл-Әсвәд (Кара үлем) кушаматлы бирәү өенә кереп, Госман бине Гаффәнны буа башлый, аннан соң кылыч белән суга. Госман сакланыр өчен кулын алга таба сузгач, ул кылычы белән аның кулын өзә. Госман бине Гаффән тын алып: «Бу Коръәннең кечкенә сүрәләрен язган беренче кул», – дип әйтә. Кайчандыр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа әйтеп торып Коръәнне яздырткан булган. Госман разыйаллаһу ганһене Коръән укыган чагында ханҗәр белән кадап үтерәләр. Ярасыннан саркыган кан алдында яткан Коръәнгә, Аллаһның түбәндәге сүзләренә тамган:

**«…сиңа ярдәм бирергә Аллаһ үзе җитәдер. Ул ишетүче һәм белүче».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:137

Шул рәвешле, Госман разыйаллаһу ганһе 35 нче һиҗри елда, зөлхиҗҗә аеның 18 нче көнендә, 82 яшендә шәһид булып китә. Җеназа намазын аңа үзенең васыяте буенча Зөбәер бине Гаввам укый.

■ «Шура» №22

# Пәйгамбәребезнең яраткан җимеше – хөрмә



Мөселман халкында элек-электән калган бер гореф-гадәт бар: яңа туган сабыйның авызына хөрмә суын, йә әйбәтләп чәйнәлгән хөрмәнең бер кисәген салып алу. Бу гореф-гадәт кенә түгел, бу – пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламнең сөннәте. Аны икенче төрле тәхник дип тә атыйлар. Бу гамәлне, гадәттә, бер тәкъва мөселман башкара. Шулай ук хөрмә урынына шикәр яки йөзем җимеше дә кулланырга мөмкин, әмма хөрмә куллану күркәмрәк санала. Пәйгамбәребезнең хатыны Гайшә анабыздан тапшырылган хәдистә болай дип әйтелә: «Яңа туган сабыйларны Аллаһның илчесе янына алып киләләр иде. Ул алар өчен хәерле догалар кыла һәм авызларына өлгергән хөрмә суы сыга иде» (Имам Бохари). Пәйгамбәребез балаларны бик ярата торган булган, ул үзенең игътибарын оныкларына гына түгел, башка мөселманнарның да балаларына бүләк итә торган булган.

Бу сөннәт бүгенге көндә дә дәвам итә. Гомумән алганда, һәрбер сөннәт гамәл – игелеккә, яхшылыкка илтә торган юл. Юкка гына Коръәндә: **«Ий, Мөхәммәд, Без сине галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек»**, – дип әйтелми. Медицина галимнәре бу сөннәт гамәлен дә тикшереп карагач: «Балага баллы җимеш каптыргач, аның авыртуы басыла һәм йөрәк тибеше нормальләшә», – дип әйткәннәр. Мәсәлән, бала туып, 7 көн үткәч, «сөннәткә утырту» йоласы башкарыла. Британия галимнәре бик күптәннән бу йоланың да баллы әйбер капканнан соң җиңелрәк үтүе турында язып чыкканнар иде инде. Бу тема ахырга кадәр ачык булмаганлыгы аркасында бик күп галимнәр өчен эзләнү өчен җирлек тудырды. 1995 елда ук кызыклы бер эксперимент үткәрәләр. Кан анализы алыр алдыннан бер төркем балаларга баллы сироп, ә бер төркем балаларга гади су эчерәләр. Әле генә туган сабыйлардан анализны сары авыруын тикшерү өчен алалар. Сироп капкан балалар гади су капкан балаларга караганда азрак елыйлар һәм аларның йөрәк тибеше дә тизрәк нормаль халәткә кайта.

Пәйгамбәребезнең бер генә гамәлне дә болай гына эшләмәве шушы тикшеренүләрдән дә күренә. Ә аның гамәлләре турында мәшһүр хәдисләр туплаучыларның – имам Бохари һәм Мөслимләрнең китапларыннан укып белеп була. Әбү Муса Әбү Борайдадан мондый хәдис тапшыра: «Минем балам тугач, мин аны пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам янына алып килдем. Ул аңа Ибраһим дип исем кушты. Шуннан соң пәйгамбәребез Мөхәммәд хөрмә җимешен чәйнәп, аның белән баланың авыз эчлеген сөртеп алды». Бу китапларда моңа охшаш хәдисләр, әлбәттә, бик еш очрый.

## Хөрмә – витаминнар сандыгы

Хөрмә җимеше составында 70-80% шикәр бар: моңа җиңел үзләштерелә торган һәм баш мие өчен бик файдалы булган һәм бик күп калорияле фруктоза һәм глюкоза керә. Шулай ук хөрмә составында 2,2 % аксым, А, В1, В2 витаминнары; калий, натрий, тимер, бакыр һ.б. химик элементлар бар. Туган вакытта да, сөннәткә утырткан вакытта да кан тамырларындагы канның агышы яхшы булсын өчен, калий химик элементының роле бик зур.

Олыларга хөрмә кирәкме соң алайса? Әлбәттә, кирәк. Рамазан аенда фарыз уразаларын, шулай ук нәфел уразаларын тоткан кеше авызны хөрмә белән ачарга ияләшкән. Ягъни хөрмәне ахшам намазы укыганчы, ашарга утырганчы ук ашап куярга кирәк. Бу сөннәт булып тора һәм шулай ук медицина галимнәре тарафыннан да шулай эшләүнең файдалы булуы расланган, чөнки ул җиңел үзләштерелә торган ризык буларак ач организмга авырлык китерми. Гомумән, табибләр көнне хөрмә ашаудан башларга да тәкъдим итәләр. Ә Пәйгамбәрбезнең ашарга булмаган көннәрдә хөрмә белән берничә көн ураза тотуы – аларның бик туклыклы икәнлеге турында сөйли.

## Коръән Кәримдә хөрмә җимеше

Аллаһы Тәгалә хөрмә турында Коръәндә 20ләп җирдә искә ала:

**«Вә ул су белән безгә иген, зәйтүн агачы, хөрмә агачы, йөзем агачлары вә башка төрле җимешләрне үстерер; фикерле белгән кешеләр өчен бу әйтелгән нәрсәләрдә Аллаһны тану өчен дәресләр бар».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:11

Шулай ук: **«Арагыздан берәрегез елгалар агып, хөрмә һәм йөзем җимешләре үсеп торган бакчаның булуын яратырмы? Әлбәттә, яратырсыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:266

Аллаһы Тәгалә җирдә үскән барлык җиләк-җимешләрдән хөрмәне аерып, болай дип әйтә: **«Ул җирдә төрле җимешләр бар һәм хөрмә җимешенең кабыклары иясе булган хөрмә агачлары бардыр».**

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:11

Хөрмә агачының Мәрьям анага ризык булуы турында Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип искә ала: **«Йә Мәрьям, хөрмә агачының кәүсәсеннән тотып үзеңә таба селкет, ул сиңа яңа өлгергән хөрмә җимешен төшерер. Ул хөрмәне аша вә чишмә суын эч».**

«Мәрьям», 19:25-26

Аллаһы Тәгалә Мәрьям анага Гайсә галәйһис-сәламне табар алдыннан шушы сүзләрне әйтә. Тәфсир кылучылар бу аятькә: «Мәрьямгә агачта килеш өлгергән, ягъни киптерелмәгән хөрмәләр, саф сулы чишмәләр бирелә. Шуңа күрә аңа: «Хөрмәләрне аша, чишмәдән су эч һәм үзеңнең малаең тууы белән шатлан», – дип әйтелә дә. Бу аятьтән чыгып, Мәрьямнең ашарга ризык таба алганлыгын һәм шулай ук бала тапкандагы авыртуны тоймавын әйтеп була. Шулай ук Мәрьямгә беркем белән дә сөйләшмәскә кушыла, чөнки кешеләр Гайсәнең ничек тууы турында барыбер күп сораулар бирерләр иде. Мәрьям аларга сөйләп бирсә дә, аларның ышанулары шик астында булганга, аңа сөйләшмәскә кушыла. Ә инде аның гаебе булмавын бүтән төрле могҗиза исбатлавы әйбәтрәк булганлыктан, Аллаһы Тәгалә Гайсәне сабый килеш үк сөйләштереп күрсәтте», – дип аңлатма бирәләр.

## Дару урынына – хөрмә

Шулай итеп, баллы әйбер авыртуны баса ала торган бер дару кебек, дип нәтиҗә ясасак та була. Ә инде баллы ризыклар арасыннан иң күркәмнәре булып җиләк-җимешләр санала. Пәйгамбәребезнең сөннәтендә баллы әйберләрдән балны һәм хөрмәләрне искә төшереп булыр иде. Аның хәдисләрендә: «Балдан да яхшырак дару юк»; «Яшь аналар өчен иң яхшы дару – яңа гына өзелгән хөрмәләр, ә олыраклар өчен – бал», – дип әйтелә.

***

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә: **«Аллаһы Тәгаләнең хаклыгы һәм бер генә икәнлеге вә Коръән Аллаһ китабы вә Мөхәммәд Аллаһның расүле икәнлеге ачыклангачы Безнең кодрәтебезгә вә берлегебезгә дәлаләт иткән ачык вә көчле галәмәтләребезне кешеләргә бөтен галәм төзелешенең хәлләреннән, вә кешеләрнең яратылышы Аллаһ эше икәнлеген үзләренең төзелешеннән чыгып күрсәтербез. Әллә һәрнәрсәгә шаһит булырга синең Раббың җитмиме?»**

«Фүссиләт / Аңлатылды», 41:53

Ягъни, әгәр дә кеше Коръән китабында шикләнә башласа, Аллаһы Тәгалә ул кешегә булышачак, аңа төрле дәлилләр күрсәтәчәк. Кеше шул дәлилләр аркасында Аллаһы Тәгаләнең кеше өчен барлыкка китергән нигъмәтләрен күрәчәк, таный башлаячак. Шулай ук Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезнең иңдерелүе хак икәне турында Үзе үк бик күп тапкырлар әйтә килде: ул – галәмнәр өчен рәхмәт; ул – мөэминнәрне җәннәт белән шатландыручы; ул – Аллаһның бүләкләрен безгә аңлатып бирүче. Пәйгамбәребез нәрсә турында гына яхшы яктан искә алмасын, ул әйбердә бәрәкәт бар. Хөрмә белән дә шулай ук.

**Сәхифәне Габделхәким Фәсхи әзерләде**

# Уңышка ирешү сере

Искәндәр абый өстәл янына утырып, тәмләп кенә чәй эчәргә җыенган мәлдә, ишегалдында күрше егете Рөстәмнең хәвефле тавышы ишетелде:

– Абый! Абый! Чык әле тизрәк, абый! Харап булды бит, ә, харап булды-ы!..

Теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалып, Искәндәр абый аш бүлмәсенең ачык тәрәзәсеннән башын чыгарды да, чәеннән бүлдергән күршесенә ачулы караш ташлап, канәгатьсез мыгырдап куйды:

– Йә, нәрсә булды тагын?

Кабаланып йөгергәннән тыны беткән егет нәкъ тәрәзә каршысында туктап тирән сулыш алды да, кулы белән урам якка ишарәләп, коты чыккан кыяфәттә бер киртәгә, бер күрше абыйсына текәлеп:

– Анда… коеда… анда сезнең кәҗәгез коега егылып төшкән, Искәндәр абый! – диде.

– Вәйт сиңа мә! – дип әллә ни исе китмәгәндәй сөйләнеп куйган абзыйның хатыны Рауза апа шомлы хәбәрне ишетүгә илерә үк башлады:

– Үлә-әм! Кайсысы-ы? Исәнме-е?!

Аннары тәрәзә янында аптырашлы халәттә басып торган иренә дәште:

– Күр әле моны, ә? Ник басып торасың!? Әллә йөрәгең дә җонланганмы?! Йөгер әйдә тизрәк!

Әмма Искәндәр абый бернинди хис-эмоцияне чагылдырмаган кызыл йөзен хатынына таба борып, кыска гына ике җөмлә әйтү белән чикләнде:

– Син, әйдә, кысылма! Юкса, кысылып калуың бар…

Язмыш шаяруы дигәндәй, Искәндәр абыйларның кәҗәсе мал табибы Фәнзилнең капка алдындагы иске коесына егылып төшә. Ишегалларында яңа кое казыткannan соң, урамдагысы ташландык хәлгә килгән була. Ни чылбыры, хәтта куласасы да булмаган шул иске коены күргәч, Искәндәр абый «хым» дип кенә әйтеп куя да, уйга чума.

– Нишләтәсең инде аны хәзер? – диде ветеринар, кулларын як-якка җәеп. – Кәҗә бит ул болан кебек нәзек һәм бик куркак хайван, инде егылып төшкәнче үк җан биргәндер…

Әмма кое төбеннән кызганыч тавышлы «Мә-ә-ә!» дигән аваз ишетелгәч, җыелган күрше-күлән моның болай түгеллегенә инанды. Ветврач исә институтта алган белемнәрен «җигеп», үз сүзендә торуын дәвам итте:

– Моның кадәр биеклектән егылып төшкән малның рәте калмый инде аның! Имгәнгәндер, аяклары сынгандыр… Кыскасы… Миңа бу кое барыбер кирәкми: кәҗәсе-ние белән бергә күмеп куйыйк та – шуның белән вәссәләм!

Шушы гадәти булмаган тәкъдимне ишеткәч, кәҗә хуҗасы беравык нәрсә әйтергә белмичә аптырап басып торды: әүвәл бимазаланудан хафага калган карчыгы Раузаны исенә төшереп, кәҗәне ничек тә чыгарасы иде дип уйлап куйса, соңыннан малкайны интектереп, аны чиләнеп чыгарганны күз алдына китергәч, Фәнзил фикере ничектер дөресрәк тоела башлады. Ә инде табиб: «Гаеп миндә дә бар – ыстрахуфканың бер өлешен бирермен» дип вәгъдә иткәч, Искәндәр абый аның белән ризалашмыйча булмас, дигән катгый нәтиҗәгә килде.

Килешенде – бетте-китте: янәшәдәге чүп үләне каплаган иске балчык өемен актарып, Рөстәм белән Фәнзил ике көрәкләп коены күмә башлагач, нечкә күңеллеләр «аһ» итте.

– Ужжыыс… – диеште кызлар, күзләрен түгәрәкләп һәм авызларын кул белән каплап. Әмма хәлнең бик киеренке булуына карамастан, чагыштырмача тыныч торган адәмнәрдән аермалы буларак, өстәгеләр нәрсә эшли башлаганын абайлаган кәҗә ачыргаланып акырырга тотынды. Аның «М-мә-ә-ә!» дигән авазы бу мизгелдә күпләргә «Күм-мәәә!!! Күм-мәәә!!!» дип ишетелде. Ләкин нишләмәк кирәк – мәсьәлә хәл ителгән: күмәсе тәк күмәсе.

Озак вакыт узмый – бахыр малкай кычкырудан туктый, дөнья тынычланып киткәндәй була. Бераздан Рөстәм белән Фәнзилгә катырак бәгырьле күрше егетләре дә ярдәмгә килгәч, эш тизләтелә, ә инде коеның яртысыннан күбрәге күмелгәч, Фәнзил, эшне туктатып, башын аска иеп эчкә карап ала да… нәрсәгәдер бик шаккатып, гаҗәпләнүеннән сызгырып куя. Шуннан соң башкалар да кызыксынып аска карый, һәм коега атылган балчык өстендә аягында басып торган канәгать кыяфәтле исән-имин кәҗәне күргәч, үзләре дә сизмәстән шулай ук сызгырып җибәрәләр.

– Вәйт иты да-а! – дип гаҗәпсенеп әйтеп куя хәйран калган Искәндәр абый.

Хәлнең хикмәте нәрсәдә булуын



аңлап алган егетләр коега тагын берничә көрәк балчык ата, кәҗә исә өстенә атылган балчыкны селкеп төшерә дә, аяклары белән төйгечләп, тыгызлап куя. Моны күргән авыл агай-энеләре түзми һәм «Сүбехәәнәллаһ – мәә шәәллаһ!» – дип тел шартлатып, коега балчык атуларын дәвам итә. Кәҗә дә тырышып үз эшен башкара. Шулай итеп, озак вакыт та үтми, кое ахырына кадәр күмелеп килгәндә, Искәндәр абыйларның газиз малкайлары өскә чыга. Янәшәдәге тактага сикереп төшкән кәҗәне авыл халкы кул чабып каршы ала.

Шушы искиткеч кызык вакыйга күпләр өчен зур гыйбрәт була. Авыл имамы Җомга намазында бу хәлне искә төшереп, шундый аңлатма бирә:

– Һәр кешенең тормышында проблемалар булмыйча калмый. Авырлыклар, бәла-казалар рәвешендәге «балчык» өстебезгә гел коелып тора. Әмма шуны аңлау мөһим: безгә килгән һәр авырлык ул – уңышка ирешү өчен бер адым, чөнки шушы авырлыкларны «селкеп төшерү» нәтиҗәсендә этәрелеп алга таба кузгалып китәр өчен үзенчәлекле бер «мәйданчык» барлыкка килә.Тормыш юлыннан атлаганда һәркем Фәнзилнең коесы кебек тирән караңгы чокырга да егылып төшәргә мөмкин. Шул вакытта өстебезгә коелган, бик куркыныч тоелган кыенлыклар «балчыгын» өстән каккалап, тыгызлап куярга һәм шулай итеп, әкрен генә булса да өскә күтәрелергә кирәк. Искәндәрләрнең кәҗәсе нәкъ шулай эшләп, сезгә бик яхшы сабак биргәнен онытасы түгел, җәмәгать, онытасы түгел…

## Локман Хәким нәсыйхәтләре

*Локман Хәким – Коръәндә искә алына торган хикмәт иясе. Ул кара тәнле, ямьсезрәк чырайлы кеше булса да, бик акыллы, нык иманлы, тәкъва булуы белән аерылып торган. Көннәрдән бер көнне аннан киңәш алырга дип килгән бер кеше хикмәт иясенең иләм-сезлегенә аптырап түзми һәм: «Йөзең шундый ямьсез, килбәтсез икән!» – дип әйтеп куя. Моңа каршы исә Локман Хәким болай ди: «Син минем йөземне тәнкыйтьлисеңме, әллә аны бар кылган Раббым Аллаһы Тәгаләнеме?» Башка кешеләр йә уңайсызланып, йә ачуланып калган шундый очракларда, хикмәт иясе менә шундый тирән мәгънәле җаваплар биргән. Күпләргә Локман Хәким үз улына җиткергән хикмәтле нәсыйхәтләре аша таныш. Шушы нәсыйхәтләрнең тагын берничәсен укучыларга тәкъдим итәбез.*

* Миңа таш күтәрергә һәм тимер ташырга туры килде, ләкин әҗәттән дә авыррак йөк күргәнем булмады. Тәмле ризык һәм җиләк-җимешләр бик күп ашап караганым булды, ләкин бу дөньяда сәламәтлектән дә татлырак нәрсә юк икәненә инандым.

* Ялганлый торган кешенең йөзеннән матурлык китәр. Башкаларга начар холык күрсәткән кешенең күңелен боегу һәм хәсрәт тойгысы биләп алыр.

* Иң зур байлык – саулык, иң зур нигъмәт – канәгать булу.

* Сүзләрең гел күңелле, йөзең исә гади һәм ачык булса, башкалар сине үзләренә бүләк бирүче кешеләрдән дә якынрак күрер.

* Дөрестән дә, әйткән сүзләремә үкенергә туры килгәләде, ләкин дәшмичә калуыма беркайчан үкенгәнем булмады.

* Синең белән үзеңә ошаган яки ошамаган нинди дә булса хәл килеп чыкса, беркайчан да артык сөенмә һәм көенмә. Борчулы хәлләрдә исә йөрәгеңә «Башкача эшләгән булсам, болай килеп чыкмас иде», дигән фикерне кертүдән саклан. Нәрсә генә булса да: «Хәерлегә булсын, монда ниндидер хикмәт бар», – дип әйт…

■ **Ришат хәзрәт Курамшин, Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

## Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд Әл-Кудагыйның «Дакаикуль-әхбәр» исемле китабы нәшер ителде



«Хозур» нәшрият йорты Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд Әл-Кудагыйның «Дакаикуль-әхбәр» исемле китабын нәшер итте. Бу хезмәт һәркемне кызыксындырган үлем һәм ахирәт белән бәйле булган сорауларга җавап бирә. Коръән аятьләре һәм Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам хәдисләренә таянып, вәгазь-нәсыйхәтләр рәвешендә язылган әсәр адәм балаларына тормышка җитди карарга, камилләшергә, тәкъвалыгы һәм ихласлыгын арттырып, Аллаһы Тәгаләгә якынаерга этәргеч булып тора.

**Китапны http://huzurshop.ru сайтыннан яки Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт (РИИ бинасы) адресы буенча урнашкан кибеттән алырга мөмкин. Телефон: +7 (903) 305-45-43**

КРАСИВЕЙШИЕ СВИДЕТЕЛЬСТВА НИКАХ!
ОБЛОЖКА С ЗОЛОТЫМ И СЕРЕБРЯННЫМ ТИСНЕНИЕМ
ВЫСОКОКАЧЕСТВЕННАЯ МНОГОЦВЕТНАЯ ПЕЧАТЬ



• Работаем по всей России
• Приобрести можно со склада от 1 штуки
• Для мечетей возможно индивидуальное клише

ВКонтакте: vk.com/nikah_docs Инстаграм: @nikah_svidetelstva
г. Казань, ул. Миславского, д. 9, офис 315
г. Казань, ул. Каюма Насыри, д. 25, цокольный этаж
тел. 8(843)292-24-22, 8-905-317-88-87

дин вә мәгыйшәт

«ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ» ГАЗЕТАСЫНА
2018 елның икенче яртысына язылу башланды

- Газета айга бер тапкыр чыга
- Ярты елга язылу бәясе: 132 сум
- Язылу индексы: П4333
- Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин: podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru сайтының «Подписка» бүлегендә.

Белешмәләр өчен телефон: 598 09 42



## КАЗАН ӨЧЕН ОКТЯБРЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз: Сәхәр тәмам | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.10.2018 | 03:40 | 04:15 | 05:45 | 12:00 | 15:19 | 17:19 | 19:01 |
| 02.10.2018 | 03:43 | 04:17 | 05:47 | 12:00 | 15:16 | 17:17 | 18:58 |
| 03.10.2018 | 03:45 | 04:19 | 05:49 | 12:00 | 15:14 | 17:14 | 18:55 |
| 04.10.2018 | 03:47 | 04:21 | 05:51 | 12:00 | 15:12 | 17:11 | 18:53 |
| 05.10.2018 | 03:49 | 04:23 | 05:53 | 12:00 | 15:10 | 17:09 | 18:50 |
| 06.10.2018 | 03:51 | 04:25 | 05:55 | 12:00 | 15:07 | 17:06 | 18:47 |
| 07.10.2018 | 03:53 | 04:27 | 05:57 | 12:00 | 15:05 | 17:04 | 18:45 |
| 08.10.2018 | 03:56 | 04:29 | 05:59 | 12:00 | 15:03 | 17:01 | 18:42 |
| 09.10.2018 | 03:58 | 04:31 | 06:01 | 12:00 | 15:01 | 16:59 | 18:40 |
| 10.10.2018 | 04:00 | 04:33 | 06:03 | 12:00 | 14:58 | 16:56 | 18:37 |
| 11.10.2018 | 04:02 | 04:35 | 06:05 | 12:00 | 14:56 | 16:54 | 18:35 |
| 12.10.2018 | 04:04 | 04:37 | 06:07 | 12:00 | 14:54 | 16:51 | 18:32 |
| 13.10.2018 | 04:06 | 04:39 | 06:09 | 12:00 | 14:51 | 16:48 | 18:30 |
| 14.10.2018 | 04:08 | 04:41 | 06:11 | 12:00 | 14:49 | 16:46 | 18:27 |
| 15.10.2018 | 04:10 | 04:43 | 06:13 | 12:00 | 14:47 | 16:44 | 18:25 |
| 16.10.2018 | 04:12 | 04:45 | 06:15 | 12:00 | 14:45 | 16:41 | 18:22 |
| 17.10.2018 | 04:14 | 04:47 | 06:17 | 12:00 | 14:43 | 16:39 | 18:20 |
| 18.10.2018 | 04:16 | 04:49 | 06:19 | 12:00 | 14:40 | 16:36 | 18:18 |
| 19.10.2018 | 04:18 | 04:51 | 06:21 | 12:00 | 14:38 | 16:34 | 18:15 |
| 20.10.2018 | 04:20 | 04:53 | 06:23 | 12:00 | 14:36 | 16:31 | 18:13 |
| 21.10.2018 | 04:22 | 04:55 | 06:25 | 12:00 | 14:34 | 16:29 | 18:11 |
| 22.10.2018 | 04:24 | 04:58 | 06:28 | 12:00 | 14:32 | 16:27 | 18:09 |
| 23.10.2018 | 04:26 | 05:00 | 06:30 | 12:00 | 14:29 | 16:24 | 18:06 |
| 24.10.2018 | 04:28 | 05:02 | 06:32 | 12:00 | 14:27 | 16:22 | 18:04 |
| 25.10.2018 | 04:30 | 05:04 | 06:34 | 12:00 | 14:25 | 16:20 | 18:02 |
| 26.10.2018 | 04:31 | 05:06 | 06:36 | 12:00 | 14:23 | 16:17 | 18:00 |
| 27.10.2018 | 04:33 | 05:08 | 06:38 | 12:00 | 14:21 | 16:15 | 17:58 |
| 28.10.2018 | 04:35 | 05:10 | 06:40 | 12:00 | 14:19 | 16:13 | 17:56 |
| 29.10.2018 | 04:37 | 05:12 | 06:42 | 12:00 | 14:17 | 16:10 | 17:54 |
| 30.10.2018 | 04:39 | 05:14 | 06:44 | 12:00 | 14:15 | 16:08 | 17:52 |
| 31.10.2018 | 04:41 | 05:16 | 06:46 | 12:00 | 14:13 | 16:06 | 17:50 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Сентябрь саны, №9 (278)*

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2753
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 27 нче сентябрьдә таратыла.
График буенча бу санга 26 нчы сентябрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.